ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ МӘГАРИФ ИДАРӘСЕ

# « МЕТОДИК ЭШКӘРТМӘЛӘР ҖЫЕНТЫГЫ»




Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы
белем бирү оешмаларының
татар теленә өйрәтүче тәрбиячеләре,
тата теле һәм әдәбияты укытучыларының
эш тәҗрибәсеннән

*Россия Федерациясендә Гаилә елына һәм*
*Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы игълан иткән*
*Шәхесләр елына багышлана*

**2024**

**Проект җитәкчесе:**

***Шәмсетдинова Р.Р.,*** *Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, доөент, филология фәннәре кандидаты*

**Төзүчеләр:**
***Шатская М.Н.,*** *Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе информацион-методик булеге начальнигы*

***Сәлахова Р.А.,*** *Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе информацион-методик булегенең милли мәгариф һәм төбәкара хезмәттәшлек буенча методисты*

***Гордеева С.К.,*** *Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе информацион-методик булегенең мәктәпкәчә белем бирү буенча методисты*

***Сәлахова З.Ү.,*** *«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы 5 нче гимназиясе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең милли эшләр буенча директор урынбасары, югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

***Зәйнуллина Р.К.,*** *«Татарстан Республикасы Зеленодольск мунииципаль районы Советлар Союзы Герое В.Х. Хаҗиев исемендәге 7 нче мәктәп» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең милли эшләр буенча директор урынбасары¸ югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

«ТАТАР ТЕЛЕ һәм ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕ МЕТОДИК ЭШКӘРТМӘЛӘРЕ». Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы белем бирү оешмаларының татар теленә өйрәтүче тәрбиячеләре, татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эш тәҗрибәсеннән: метродик кулланма, 2024. - 52 б.

**«Туган телгә өйрәтүнең сыйфатын күтәрү юллары»**

*Сәлахова Роза Абрар кызы,*
*Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсенең информацион-методик бүлегенең югары квалификацион категорияле методисты*

Телләр безнең матди һәм рухи мирасыбызны саклау һәм үстерүнең көчле коралы булып тора. Туган телләр, кешенең күп кенә телләрне үзләштерүенә карамастан, беркайчан да юкка чыкмаячак әйберләрне аерым күзаллау белән тәкъдим итеп, туган телләрнең һәр кешегә нинди эз салулары белән уникаль. Мәктәптә туган телне өйрәнү кирәк, чөнки үз туган телен белгән һәм хөрмәт иткән кеше генә башка мәдәниятне хөрмәт итә һәм бәяли ала.

Туган телләрне укыту безнең заманча дөньяда бик мөһим. Бүген, балалар әкренләп рус теленә күчкәч, укытучыларга, туган телдә дөрес сөйләшергә генә түгел, туган телне сыйфатлы өйрәтергә дә кирәк. Туган телне өйрәнү - озак вакыт һәм түземлек таләп итә торган процесс ул.

«Туган тел һәм туган әдәбият» дигән фән өлкәсен өйрәнү түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

- мәдәният сакчысы буларак туган телгә һәм туган әдәбиятка карата кыйммәтле мөнәсәбәт тәрбияләү, үз халкының мәдәни-тел кырына кертү;
- үз халкының әдәби мирасын берләштерү;
- үз халкының казанышларына һәм традицияләренә катнашы булуны формалаштыру, буыннарның тарихи дәвамлылыгын аңлау, халыкның мәдәниятен саклап калу өчен үз җаваплылыгын аңлау;
- система һәм үсештәге күренеш буларак, аның дәрәҗәләре һәм берәмлекләре турында, аның яшәеш закончалыклары турында белемнәр алу, лингвистиканың база төшенчәләрен үзләштерү, тел берәмлекләренә һәм төрле функциональ-мәгънәви типтагы текстларга һәм жанрларга карата аналитик белем формалаштыру.

Туган телне өйрәнгәндә, балалар туган як тарихы турында күбрәк белә, халык мәдәниятенә якын килә, укытучылар үз эшләрендә актив куллана торган төрле методлар, укыту алымнары моңа ярдәм итә.

Туган телгә өйрәтүнең сыйфатын күтәрү өчен, укытуның түбәндәге методларын һәм формаларын кулланырга мөмкин:

1. Дәресләрнең традицион булмаган актив формалары. Туган телне уңышлы үзләштерүгә ярдәм итә торган иң нәтиҗәле ысулларның берсе - дәресләрнең традицион булмаган актив формалары. Мондый дәрескә дәрес-

конференция, матбугат конференциясе, дискуссия, ток-шоу, дәрес-телемост, диалог, экскурсия, читтән торып сәяхәт, уку конференциясе, һөнәрне яклау дәресе, рольле уен һ.б. керә. Иң элек укытучыга әлеге дәресләрне аера белергә һәм аларның һәркайсының үзенчәлеген белергә, аларны әзерләү методикасын һәм үткәрү технологиясен белергә кирәк.

2. Белем бирүнең сыйфатын арттыру факторы буларак яңа педагогик технологияләр куллану, укытуны индивидуальләштерү һәм социальләштерү. Инновацион педагогик технологияләр куллану дәреснең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын сизелерлек арттыра. Мәсәлән, интерактив тактадан файдалану - презентацияләр, электрон дәреслекләр, видеофильмнар, укучыларның мотивациясен сизелерлек арттыра.

3. Укучыны сыйныфтан тыш эш процессына кертү. Сыйныфтан тыш эшкә җитди игътибар биреп, без аның уңай нәтиҗәсенә өметләнергә хаклы. Укучыларда туган телне өйрәнүгә тотрыклы кызыксыну формалаша. Сыйныфтан тыш эшләү укучыларга сөйләшүнең практик күнекмәләре дәрәҗәсен камилләштерергә ярдәм итә, аларның дөньяга карашын киңәйтә, иҗади сәләтләрен үстерә һ.б. Сыйныф бүлмәсенә мөнәсәбәттә эзлеклелек белән характерлана торган тышкы эш укучыларга өйрәнелә торган туган телнең чын мөмкинлекләрен күрергә һәм аларны «мәктәп өчен түгел, ә тормыш өчен» өйрәнүләренә ышандырырга ярдәм итәргә тиеш. Сыйныфтан тыш эшләү үзенең мавыктыргыч формалары белән билгеле бер эмоциональ халәт тудыра һәм укучыларны мотивацияләүнең көчле рычагы булып тора.

4. ИКТ куллану. ИКТ куллану укытучыдан эш формаларын һәм ысулларын яңадан аңлауны таләп итә. Аңлашыла ки, яңа мультимедиа технологияләре, әгәр алар алдынгы методик алымнар белән ныгытылса, туган телгә өйрәтүнең югары тәэсирен бирә. Укыту процессында хәзерге вакытта иң югары тәртипнең техник чарасы булган компьютерны куллану - укытучының техник коралланышын үзгәртү генә түгел - бу аның ролен яңарту, аның педагогик карашлары һәм алымнары складын үзгәртү, аның үз белемнәрен һәм тәҗрибәсен яңа чаралар белән тапшырырга әзерлеге. Бу яңа шартларда үз һөнәри эшчәнлекләрен башкарырга әзерлек. Бу яңа төрдәге педагогик мәдәният, мәгариф эчтәлеген, алымнарны һәм методларны, укытуның оештыру формаларын яңартуны таләп итә.

5. Интернет-ресурслардан файдалану. Бүгенге көндә туган тел укытучысы Интернет-ресурсларны да яхшы белә белергә тиеш, алар туган телне аның чыганаклары белән бердәмлектә үзләштерүне тәэмин итәләр, шулай ук укытучы эшен сизелерлек дәрәҗәдә җиңеләйтәләр, укытуның нәтиҗәлелеген арттыралар, укытуның сыйфатын яхшыртырга мөмкинлек бирәләр.

Шулай итеп, туган телләрне өйрәнү - ул белем бирүнең һәм уңышлы шәхес тәрбияләүнең аерылгысыз һәм кирәкле өлеше, һәм бер-берсе белән килешеп яшәргә сәләтле җәмгыять.

## БАЛАЛАР БАКЧАЛАРЫНДА ТАТАР ТЕЛЕНӘ ӨЙРӘТҮ

### «Әбинең туган көне»

*Баһавиева Гөлнара Фирдәвес кызы,*
*Тататарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының*
*«21 нче «Күгәрчен күзе » балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең югары квалификацион категорияле татар теленә өйрәтүче тәрбиячесе*

**Максат:** балаларның сөйләмен көнкүрешкә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү; дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Бурычлар**: 1. Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү ( ягымлы сүзләр әйтү, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкяр итү, раслау)

2. Балаларны мөстәкыйль фикер йөртергә, сорау һәм аңа дөрес җавап бирергә күнектерү. Балада үзенең сөйләменә карата кызыксыну һәм сизгерлек уяту.

3. Сөйләм әдәбе (туган көн табыны артында) кагыйдәләрен камилләштерү.

**Сүзлек:** кунаклар – гости, кош теле – хворост, бавырсак, гөбәдия - губадия

**Җиһазлау:** туп, төсле шарлар, савыт-саба, туган көн табыны өчен ашамлыклар, эчемлекләр, милли ризыклар; җырлыйм, биим пиктограммалары.

**Техник чаралар:** магнитофон, ноутбук, проектор, интерактив такта, әбидән электрон хат.

**Кулланылган әдәбият:** аудио диск "Шома бас", "Без инде хәзер зурлар мәктәпкә илтә юллар – 58 кисәк"; "Әбием, әбекәем", "Хәерле иртә", "Ак калач", "Кулыңны бир кулыма" язмалары; "җырлыйм, биим" пиктограммалары.

**Белем бирү өлкәсе:** әдәби-нәфәсәти, танып белү, сөйләм үстерү

**Белем бирү эшчәнлегенең барышы:**

**Тәрбияче:** Исәнмесез, балалар.

**Балалар:** Исәнмесез.

**Тәрбияче:** Балалар, бер-беребезгә елмаеп хәерле иртә теләп алыйк.

**<u>Сүзле уен “Хәерле иртә”</u>**

(тупны бер-берсенә биреп “хәерле иртә” телиләр)

**<u>Җыр «Хәерле иртә»</u>**

**Тәрбияче:** Балалар, килегез монда, утырыгыз.

Мне на электронную почту сегодня пришло письмо от бабушки. Послушайте, что она пишет:

***<u>(просмотр звукового письма)</u>***

«Исәнмесез, балалар. Дорогие ребята, вы не забыли, что приглашены на мой день рождения, которое будет проходить в кафе «Тәмле». Я очень надеюсь, что вы приедете. Мин сезне көтеп калам. Сау булыгыз».

**Тәрбиячесе:** Балалар, вы готовы пойти на день рождения к бабушке?

**Балалар:** Әйе.

**Тәрбияче:** Әйе, барабыз. А что вы приготовили со своими родителями для нашей именинницы? (Подарки). Давайте посмотрим, кто что подарит. Валерия син нәрсә бүләк итәсең?

**Валерия:** Мин чәчәк бүләк итәм.

Әңгәмә шулай дәвам итә.

**Тәрбияче:** Чтобы создать праздничное настроение, я предлагаю взять воздушные шарики. У каждого есть свой любимый цвет. Кому какой цвет нравится?

**<u>Уен ситуациясе: «Шар бир әле»</u>**

**Тәрбияче:** Спросите у Дианы шар такого цвета, который вам нравится.

**Кира:** Диана, яшел шар бир әле.

**Диана:** Ничә шар?

**Кира:** Бер шар. (*1-10 кадәр саннар*)

**Диана:** Мә бер яшел шар.

**Кира:** Рәхмәт.

**Тәрбияче:** Кира, как ты скажешь, что тебе нравится зеленый шар?

**Кира:** Мин яшел шар яратам.

Диалог балалар арасында дәвам итә.

**Тәрбияче:** Балалар, менә хәзер туган көнгә барсак та була. Балалар, әйдәгез кафега җырлый-җырлый барыйк. Диана җырла, Артем җырла... . Әйдәгез, җырлыйбыз.

*аудио 58(б)*

Мин барам, барам, барам,
Кафега барам, барам.
Мин барам, барам, барам,
Мин туган көнгә барам.
Җырлыйм, бийм, күңел ачам,

Әбине котлап кайтам.

**Уен ситуациясе: «Әбидә туган көндә»**

Балалар кафега әбинең туган көненә киләләр.

**Әби:** Исәнмесез, балалар!

**Бергә:** Исәнме, әби! Хәлләр ничек, әби?

**Әби:** Әйбәт. Рәхмәт.

**Бергә:** С днем рождения, әби! – Туган көнең белән, әби!

**Тәрбияче:** Давайте на день рождения Әби споём песню «Каравай» - «Ак калач».

**Җыр: «Ак калач»**

Әбинең туган көненә
Без пешердек ак ипи.
Менә шундый зур ипи,
Менә шундый кечкенә.
Менә шундый тәмле,
Менә шундый баллы.
Әйе шул, әйе шул,
Әйе шул, ипи тәмле.
Котлыйбыз! Котлыйбыз! Котлыйбыз!

**Әби:** Зур рәхмәт.

**Тәрбияче:** Балалар давайте попросим Әби, чтобы она станцевала.

**Бергә:** Әби, әйдә, бие.

Әби татар халык бию көенә бии.

**Тәрбияче:** Балалар, әби нишли?

**Балалар:** Әби бии.

**Тәрбияче:** Әби ничек бии?

**Бергә:** Әби матур бии.

**Әби:** Зур рәхмәт.

**Үстерелешле диалог: «Минем бүләгем»**

Балалар әбигә үзләренең бүләкләрен бирәләр.

**Тәрбияче:** Ребята, а теперь подарим подарки Әби. Валерия, подари бабушке подарок, который ты приготовила.

Балалар бүләкләрен табып алалар, алар турында сөйләп, әбигә бүләк итәләр.

**Валерия:** Бу – чәчәк. Чәчәк матур, кызыл, чиста, зур. Мә, әби, чәчәк.

**Әби:** Зур рәхмәт.

Шул үрнәктә һәр бала бүләген әбигә бүләк итә.

**Тәрбияче:** Әби, безнең балалар биергә яраталар. Наши ребята приготовили для тебя еще один подарок – танец. Посмотри, они очень старались.

Бие пиктограммасы күрсәтелә

**Тәрбияче:** Диана, әйдә, бие! (ребёнок выходит танцевать). Диана син нишлисең?
**Диана:** Мин биим. Алёша, әйдә бие! Алёша, син нишлисең?
Дилог биюче балалар арасында шул тәртиптә дәвам итә.

**«Парлы бию»**

**Уен ситуациясе: «Туган көн табынында»**

**Әби:** Балалар, сезгә зур рәхмәт, за такое поздравление, за подарки, за красивый танец. Я Вас ждала с нетерпением, заказала много вкусного. Әйдәгез, балалар, өстәл артына утырыгыз.

(балалар өстәл артына утыралар)

**Әби:** Алёша нәрсә кирәк?
**Алёша:** чәк-чәк кирәк.
**Әби:** Нинди чәк-чәк?
**Алёша:** Тәмле, баллы, чәк-чәк.
**Әби:** Мә тәмле, баллы, чәк-чәк.
**Алёша:** Рәхмәт.
**Әби:** Алёша, син нишлисең?
**Алёша:** Мин чәк-чәк ашыйм.
**Әби:** Чәк-чәк тәмлеме?
**Алёша:** Әйе, чәк-чәк тәмле. Мин чәк-чәк яратам.
**Әби:** Кира, нәрсә кирәк?
**Кира:** чәй кирәк?
**Әби:** Нинди чәй?
**Кира:** Тәмле, баллы, чәй.
**Әби:** Мә тәмле, баллы, чәй.
**Кира:** Рәхмәт.
**Әби:** Кира, син нишлисең?
**Кира:** Мин чәй эчәм.
**Әби:** Чәй тәмлеме?
**Кира:** Әйе, чәй тәмле. Мин чәй яратам.
**Әби:** Балалар, Вы сидите за волшебным праздничным столом, будьте вежливы, угощайте друг друга.

Балалар алдагы диалог үрнәгендә бер – берсен сыйлыйлар.

**Тәрбияче:** Полина Вероникаңы сыйла!
**Полина:** Вероника нәрсә кирәк?
**Вероника:** Өчпочмак кирәк.
**Полина:** Нинди өчпочмак?
**Вероника:** Тәмле, өчпочмак аша.
**Полина:** Мә тәмле, өчпочмак.

**Вероника:** Рәхмәт.
**Полина:** Вероника, син нишлисең?
**Вероника:** Мин өчпочмак ашыйм.
**Полина:** Өчпочмак тәмлеме?
**Вероника:** Әйе, өчпочмак тәмле. Мин өчпочмак яратам.
**Тәрбияче:** Валерия син кемне сыйлыйсың?
**Валерия:** Полина, нәрсә кирәк?
**Полина:** сок кирәк?
**Валерия:** Нинди сок?
**Полина:** Тәмле, баллы, сок.
**Валерия:** Мә тәмле, баллы сок эч.
**Полина:** Рәхмәт.
**Валерия:** Полина, син нишлисең?
**Полина:** Мин сок эчәм.
**Валерия:** Сок тәмлеме?
**Полина:** Әйе, сок тәмле. Мин сок яратам.
**Тәрбияче:** Әби, безнең балалар шундый уңганнар. Они так много песен знают. И хотят подарить песню на татарском языке. Кира, син нишлисең?

(Балаларга җырлыйм пиктограммасы күрсәтелә)

**Кира:** Мин җырлыйм.
**Әби:** Роксана, син нишлисең?
**Роксана:** Мин җырлыйм.
**Тәрбияче:** Әйдәгез, бергә җырлыйбыз.
Балалар түгәрәккә басып җырлыйлар.
**Җыр: «Әбием, әбекәем»**
*Рустама Бакиров сүз. Рустам Сарваров көе*
I. Балам, дия – дия безне
Кадерләп үстерәсең,
Әй, матур син, әбекәем,
Күзләр тия күрмәсен!
*Кушымта:*
Әй, әбием, әбекәем,
Кояш кебек күңелең,
Сәламәтлек бирсен Ходай,
Озын булсын гомерең.
II.Өебезнең нуры бит син,
Рәхмәт яусын үзеңә.
Бәхетлебез, әбекәем,
Син булган өчен генә

**Әби:** Балалар, сезгә котлаулар, бүләкләр өчен, игътибарыгыз өчен зур рәхмәт. Мине онытмагыз, тагын кунакка килегез.  Сау булыгыз!

## Исем күңел көзгесе”
## (исем кушу йоласы)

мәктәпкә әзерлек төркемендә социаль-коммуникатив үсеш буенча дәрес

*Гәлләмова Рузилә Рәүф кызы,*
*Татарстан Республикасы Зеленодол районы Осиново авылының 53 нче номерлы “Шатлык” балалар бакчасының тәрбияче*

*Кыз бала исеме йолдыз балкышына охшасын,*
*назлы гөлчәчәктәй нәфис булсын.*
*Ир-ат исеме кылычлар чыңлавын хәтерләтсен,*
*аның мәгънәсендә гакыл гәүдәләнсен.*
*Рәсүл Гамзатов.*

**Максат:**
1.гореф-гадәтләребезгә, гаилә традицияләренә кызыксыну уяту;
2.буыннар бәйләнеше,исемнәр, аларның килеп чыгышы, әһәмияте турында күзаллауларын тирәнәйтү;
3.гаиләң белән горурлану хисләре, өлкәннәргә ихтирам, хөрмәт тәрбияләү;
**Бурычлар:**
Белем бирү: Татар халкының борынгыдан килгән йоласы – “Исем кушу”, “Бишек туе” турында сөйләшү. Исемнәрнең мәгънәләре  турында аңлату.
Үстерү: Балаларның саф татар телендә, чиста, аңлаешлы, дөрес сөйләшү күнекмәләрен үстерү, ныгыту. Милли йолалар турында белемнәрен киңәйтү.
Тәрбияви: Балаларда татар милләтенең йолалары, традицияләренә карата кызыксыну уяту. Бер-берсенең исеменә хөрмәт тәрбияләү. Исемнәрне бозмаска, үзгәртмәскә өйрәтү.
**Алдан башкарылган эш:** әңгәмәләр оештыру, татар халык уеннары уйнау, татар исемнәренең мәгънәсен ачыклау. Проектка доклад әзерләү.
**Җиһазлау**: проектор, экран, компьютер, аудиоязмалар, кучтәнәчләр, атрибутлар (рәсемнәр: ай, хан, китап, көзге, акча, тимер).
**Эшчәнлек барышы:**
Тәрбияче: Исәнмесез балалар!
Балалар: Исәнмесез!
Тәрбияче: Балалар без бүген сезнең белән исем кушу йоласы турында сөйләшеп алырбыз.

Халкыбызның рухи мәдәниятенә алып керүче бер чыганак- ул татар халкының милли, күркәм йолалары. Аларның берсе – исем кушу йоласы. Ул йола әле дә үткәрелә. Хәзерге буын балалары милли хәзинәбезне, ана телен саклап калсыннар өчен.

**Тәрбияче:** Рәхим-шәфкатьле булсын өлкәннәр,
Җанны җылытсын иман нурлары.
Әй, нәни кешем,өмет йолдызы,
Имин, уңбулсынбарыр юлларың.
Кул сузам сиңа, елмаеп дәшәм:
Якты дөньяга ямь биреп яшә,
Җиргә син кирәк, илгә син кирәк,
Көнгә син – терәк, исәнме, Кеше!

Бала туды. Дөньяга яңа кеше килде. Аңа кушу өчен исем кирәк. Матур исем, мәгънәле исем, зәвыклы исем – кыскасы әйбәт исем. Татар халкының дистәләрдән артык гасырларны эченә алган тоташ буыннар чылбарыннан гыйбарәт милли исемнәр тезмәсен алга таба дәвам итәрлек исем, халык рухын саклый торган милли исем кирәк.

Татар халкы элек-электән яңа туган сабыйга исем кушуга зур җаваплылык белән караган. Исеме җисеменә туры килә торган матур эчтәлекле, аһәңле, җиңел һәм анык әйтелешле исемнәр бирергә тырышкан. Яңа туган сабыйга кушу өчен исем эзләгәндә, ул исемнең җыйнак, җиңел әйтелешле, яхшы мәгънәле һәм аһәңле булырга тиешлеген истә тоту зарур булган. Күркәм исемнәребез күп булганга, һәрбер ата-ана шулар арасыннан үзенә ошаганын, зәвыгына туры, күңеленә хуш килгәнен, әлбәттә, заман таләпләренә җавап бирә торганын сайлый алган.

**Уен “Исеменә карап җисеме”**

Исемнәр үзе бер тарих. Аларны ачыклауга галимнәр зур әһәмият бирә. Әйдәгез, гыйбрәт алыр өчен генә кайбер исемнәрнең мәгънәләренә игътибар итик әле.

Балалар сезнең алдыгызда сүрәтләр(ай, көзге, тимер,акча, хан, китап, ике дус). Мин сезгә исемнәр укыйм, ә сез аларның мәгънәсен рәсемгә туры китереп җавап бирегез.

Айсылу – ай;
Әмирхан – хан;
Галим – китап;
Илдус – дуслар;
Гүзәл – көзге;
Байбулат – акча;
Тимерхан – тимер.

Тәрбияче: Балага исем кушу- җиңел эш түгел. Бала тугач, өйгә, гаиләгә яңа ямь, юаныч, куаныч, бәхет өстәлә. Шуның белән бергә яңа туган сабый ата-анасына өстәмә мәшәкатьләр дә китерә. Аларның иң беренчесе— исем кушу. Балага нинди исем бирергә? Бу сорау һәрбер ата-ананы, баланың өлкән туганнарын, кардәш-тумачаларын уйландыра, борчый. Чөнки исем кешегә бер генә мәртәбә бирелә һәм ул аның гомерлек юлдашына әверелә. Һәр кеше үз исеменә шулкадәр күнегә ки, ул аның туган теленең иң якын, иң газиз, иң кадерле сүзе булып тоела. Безнең Әмирнең әти-әнисе шул йоланы видеога яздырганнар. Әйдәгез әле бергәләп бәбигә исем кушу йоласын карап үтик.

(видео язманы карау).

Әңгәмә.

Тәрбияче:Балалар, без бүгенге дәрестә сезнең белән нинди йола белән таныштык? -Ничек атала бу йола?

Бала: Исем кушу йоласы.

Тәрбияче: Исем кушарга кемне чакырганнар?

Бала: Мулла бабайны

Тәрбияче:Ә кем соң мулла?

Бала: Ул балалар олы яшьтәге һәм догалар укучы кеше.

Тәрбияче:Ул балага исем кушканда нәрсә эшли соң?

Балалар: Балага дога укый, азан әйтә, колагына өч тапкыр исемен әйтә, шулай итеп, балага исем кушалар.

Тәрбияче: Балага нинди исем куштылар?

Балалар: Рамазан.

Тәрбияче: Рамазан исеме нәрсәне аңлата икән?

Балалар: Рамазан – ул иманлы, тәүфиклы, көчле дигәнне аңлата. Рамазан дигән исемне Рамазан аенда туган балаларга да кушалар.

Тәрбияче: Видеоязмада сез кемнәрне күрәсез? Мәҗлестә алар нәрсәләр эшлиләр?

Балалар: Әти, әни, әби, абый һәм энекәш. (Балаларһәрбересүзфикерләренәйтепчыгалар)

Тәрбияче:Аллага шөкер исем кушылды. Табынга мулла абзыйны кем чакырды?

Балалар: Әни.

Тәрбияче: Табында нинди тәмле ризыклар бар?

Балалар: Өчпочмак, чәк- чәк, кыстыбый, чәй, бал, кәнфит.
Тәрбияче: Балалар, ә сез игътибар иттегезме нинди милли киемнәрдән иде Әмирнең әти – әнисе?
Балалар: Татар халык киемнәре (тюбәтәй, калфак, күлмәк, камзол, чалбар)
Тәрбияче:Әмирнең әле безгә бүләге дә бар? Алар әти-әнисе һәм энәкеше белән бию алып килгәннәр.
Балалар сезгә өй эше бирелгән иде (балалар үз исемнәренең мәгънәләрен белеп кечкенә доклад ясыйлар) Проектларны яклау
Тәрбияче: Менә сезнең барчагызның да исемнәрегез бик матур, ә сез беләсезме сезнең исемнәрегез нәрсәне аңлата?
- Ренат, син әйтә аласыңмы?
Ренат: Әйе, минем исемем яңартылган, яңадан туган дигәнне аңлата.
Тәрбияче: Айсылу, ә син балакаем беләсеңме?
Айсылу: Әйе, ай кебек матур кызларны шулай дип әйткәннәр.
Тәрбияче: Динара, ә син?
Динара: Беләм, минем исемем алтын таш дигәнне аңлата.
Руслан:Ә минем исемем арыслан кебек көчле булуын аңлата.
Тәрбияче: Дөрес балалар, барлык исемнәрнең аңлатмасы бар. Мәсәлән Солтанның исеме хәкимлек итүче – дигәнне аңлата.
Азалия: чәчәк исеме.
Аделина: гәдел, намуслы.
Диана: илаһи.
Тәрбияче: Шулай итеп һәр бер исемнең үз аңлатмасы бар. Биктә дөрес җавып бирдегез, игътибарлы булып утырганыгызга бүгенге дәрестә мин бик шатмын. Бүгенге шөгылебез шушының белән тәмам. Татар халкының йолаларын, гореф гадәтләрен онытмасак иде. Буыннар бәйләнеше, исемнәр, аларның килеп чыгышы, мәгънәсе турында белем алдык. Сау булыгыз балалар.
Балалар: Сау булыгыз .

Кулланылган әдәбият

1. https://shahrikazan.ru/news/yazmalar/isem-anny-ber-leshe-yazmyshka-tesir-it-torgan
2.Саттаров Г.Ф. “Татар исемнәре сүзлеге” 2019 ел;
3.Лилия Дәүләтшина “Нәниләргә бишек җырлары, бармак уенныра”

# «Әкиятләр илендә кунакчыллык»

Зурлар төркемендә сөйләм телен үстерү буенча шөгыль

*Саттарова Асилә Хәнәфи кызы,*
*Татарстан Республикасы Зеленодол районы Осиново авылының 53 нче номерлы “Шатлык”балалар бакчасы тәрбияче*

**Максат**: Татар һәм урыс әкиятләре ярдәмендә, халкыбызга хас милли үзенчәлекләр: кунакчыллык, тыйнаклык, дуслык белән балаларны таныштыру.

**Белем бирү бурычлары**: “Минеке, тимә” татар әкияте белән таныштыру һәм рус халык әкияте “Балтадан пешерелгән ботка“ (“Каша из топора”) белән чагыштыру.

**Тәрбия бурычлары:** Балаларда кунакчыллык, әдәплелек сыйфатлары тәрбияләү, халкыбызның гореф- гадәтләрен хөрмәтләргә өйрәтү, табын әдәбен, үзеңне әдәпле тоту күнекмәләрен тәрбияләү.

**Үстерү бурычлары:** хәтер һәм бәйләнешле сөйләмне үстерү.

**Сүзлек өстендә эш:** күрше малае, саран, чәйнек, уенчыклар.

**Алдан эшләнген эш**: “Балтадан пешерелгән ботка”(“Каша из топора”) урыс халык әкияте белән таныштыру. Кунакчыллык турында сынамышлар өйрәнү. ”Кунаклар” уенын өйрәнү. Татар һәм урыс милли халык ризыклары белән таныштыру. “Минеке, тимә” әкиятенә атрибутлар әзерләү.

**Җиһазлар:** Курчак театры. ”Бибинур әби әкиятләре” һәм ”Сказки бабушки Матрёны” комлектыннан күрсәтмә материаллар. Приложение 1.

**Эшчәнлек барышы:**

Балалар кулга кул тотынышып, түгәрәкккә басалар. Чиратлашып янәшә басып торган иптәшләрен сәламлиләр: “Исәнме, ....!Мин сине күрүемә шат!”

-Мин дә сезне күрүемә бик шат ( балалар утырышылар)

-Балалар, бүген без татар һәм урыс халкыларының күркәм сыйфатларының берсе кунакчыллык турында сөйләшәбез. Ә сезгә балалар кунаклар киләме соң? Кунаклар килгәч сез шатланасызмы?( Балаларның җаваплары)

-Татар халкы элек-электән үк кунакчыл булган, гел кунак чакырган, кунакка йөрешкән. Сезнеңчә, кешеләр ни өчен бер-берсенә кунакка йөриләр? (Балаларның җаваплары).

-Айе, кунакка йөрешү өчен сәбәпләр бик куп. Туган көн, бәби чәе, яңа өйгә күченү, сабантуй , яңа ел бәйрәме. Бер-беребезне сагынган очракта, сәбәпсез дә кунакка чакырыга мөмкин. Безнең халкыбыз хуҗаларга хөрмәт йөзеннән кунакка һәрвакыт күчтәнәч белән йөргән. Кунакка барганда нинди күчтәнәчләр алып килергә була? (Балаларның җаваплары).

-Балалар, кунакны каршы алырга ничек әзерләнергә кирәк соң? (Балаларның җаваплары).
-Әйе, балалар, өйне чиста итеп җыештыралар, матур киемнәр кияләр, кунакларны ачык йөз белән каршы алалар, тәмле ризыклар әзерләп сыйлыйлар. Ә табын янында ничек үзеңне тотырга кирәк соң, әйдәгез искә төшерик әле? (Балаларның җаваплары: терсәкләрне өстәлгә куерга ярамый, алдан ашый башларга ярамый, кулларыңны киемгә сөртергә ярамый ,кычкырып сөйләмшергә, урындык белән уйнап утырырга ярамый, ризыкларны ашыкмыйча яхшылап чәйнәргә кирәк.)
-Татар халкы кунакларны нинди ризыклар белән сыйлый? (Балаларның җаваплары: тыкмачлы ашы, өчпочмак, чәк-чәк, каклаган каз, кыстыбый, гөбәдия, бәлеш, катык, сөтле яисә җимешле чәй)
-Кунакчыллык турында сынамышлар өйрәнгән идек, өйдәгез искә төшерик әле? (Балаларның җаваплары: Мәче битен юса, кунак килә. Өстәлдән кашык-чәнечке, пычак төшсә, кунак килә. Самовар җырласа, кунак килә. Чыпчык тәрәзәдән килеп шакыса, кунакны көт.). Әфәрин, булдырдыгыз. Әйдәгез балалар хәзер уйнап алыйк. Уйныйсыгыз киләме?
Балалар кулга-кул тотынышып, түгәрәкләнеп басалар. Уртага бер бала чыга. Кырыйдагы балалар түгәрәк буенча әйләнеп җырлыйлар:
Ямьле бәйрәм көн иде,
Чакырдык без кунаклар;
Кунакларны сыйларга,
Салдык майлы коймаклар,
Чыж-пыж итеп коймаклар,
Җәелде, әй, җәелде.(Кулларын як-якка җәяләр.)
Менә тагын кечкенә Булып калды, җыелды.(Кысылалар.)
Җыелды, әй, җыелды, Аннан ары кабарды.(Кулларын югары күтәрәләр.)
Кабарды, әй, кабарды, Шиңде, юп-юка калды.(Чүгәлиләр.)
Пеште инде коймаклар, Сыйландылар кунаклар,
Тордылар, баш иделәр, Таралдылар, әй, шатлар.(Баш ияләр.)
Бииләр, ай-яй, шатлар.
-Балалар уйнап , ял итеп алдык, ә хәзер утырышыгыз.
-Кунакчыллык турында әкиятләр бик күп. Хәтерлисезме, күптән түгел генә кунакчылллык турында без урыс халык әкияте белән танышып киткән идек. Әкиятнең исемен искә төшерегез әле, балалар (Балаларның җаваплары: “Балтадан пешерелгән ботка” (“Каша из топора“).
- Бу әкияттә карчык кунакчыл булганмы? (Балаларның җаваплары: юк, карчык кунакчыл булмаган, ул саран булган).

-Ни өчен? (Балаларның җаваплары: карчык солдатны ашатмаган, минем уземә дә ашарга юк дип әйткән).
- Ә кунакчыл кеше нишләр иде? (Балаларның җаваплары: кунакчыл кеше ачык йөз белән каршы алып, тәмле ашамлыклар белән өстәл әзерләр иде).
-Балалар, бу әкият кунак каршылый белми торган карчык турында булды, ә хәзер мин сезне бер татар әкияте белән таныштырып китәм. Бу әкияттә дә кунакчыллык турында бара. Әкиятенең исеме “Минеке, тимә” дип атала.
Тәрбияче кыз һәм малай курчагы алып, әкиятне алар ярдәмендә күрсәтә.
-Гөлгенәнең уенчыклары бик күп. Тик уйнарга бер генә иптәше юк. Буген әбисе аның белән уйнарга күрше малае Фәритне чакыра. Алар башта бик тату уйнадылар. Шунда Фәритнең матур бер уенчыкка күзе төште, аны кулына алды. Гөлгенә чырылдап кычкырып җибарде:
-Минеке, тимә!
Әбисе ана:
-Алай ярамый, бергә уйнагыз.Уенчыкларыңны бир,- диде
Гөлгенә бер аягы сынган , бер кулы чыккан курчакны бирде.Тик Фәрит аның белән озак уйнамый башка уенчыкны алырга тели. Гөлгенә яңадан:
-Минеке тимә, үзем уйныйм,- диде
Гөлгенә барлык уенчыкларын кулына алды да :
-Әйдә , теге бүлмәгә кереп уйныйк ,-диде
Фәрит аңа булышырга теләп уенчыкларны ала башлады, тик Гөлгенә
-Минеке , тимә. Үзем күтәрәм ,- диде

Ул бөтен уенчыкларын үзе генә күтәрергә теләде.Шулай кылана торгач, әнисе бүләк иткән алтын тоткалы бәләкәй чәйнеген төшереп ватты. Ватты да бик ямсез итеп еларга кереште. Әбисе килеп җитте:
-Һай, харап иттең ич. Үзең генә уйнагач, үзең генә күтәргәч, шулай була инде ул!- дигән
-Балалар, менә бу әкияттә дә кунакчыллык турында бара. Әйдәгез хәзер искә төширик әле, Фәрит уенчыкларга кагылган саен Гөлгенә нарса дип кычкыра (Балаларның җаваплары: Минеке ,тимә)
-Кыз кайсы уенчыкны вата? (Балаларның җаваплары : кыз чайнекне вата)
-Бу чәйнек ни өчен Гөлгенәгә кадерле? (Балаларның җаваплары: чәйнекне әнисе буләк иткән була)
-Сез ничек уйлыйсыз,әгәр дә Гөлгенә чайнеген Фәриткә уйнарга биреп торган булса, чәйнек ватылыр идеме? (Балаларның җаваплары: юк, чәйнек ватылмас иде).
- Гөлгенәнең, сезнеңчә, дуслары күп булганмы? Ни өчен? (Балаларның җаваплары: юк, Гөлгенәнең дуслары күп булмаган, чөнки ул саран булган, кунакчыл булмаган).

- Сезнең өйдә яраткан уенчыкларыгыз бармы.? Аның турында сөйләп китегез, кем бүләк итте яисә сатып алды сезгә. Ул нинди төстә? (Балаларның җаваплары).

-Ә сезгә дусларыгыз кунакка килгәч, аларга уенчыкларыгыз белән уйнарга рөхсәт бирәсезме? ( Балаларның җаваплары). Балалар, саран булырга ярамый, кунакчыл, юмарт булырга кирәк. Кунаклар килгәч, аларны ачык йөз белән каршы алсак, тәмле ашатсак, саранланмыйча уенчыкларыбыз белән бергә дус - тату уйнасак, дусларыбыз да күп була. Дуслар күп булгач, бу дөньяда яшәргә дә күңелле. Балалар, сез әкиятләр тыңлап утырырга бик яратасыз икән. Ә үзегезнең әкиятләр язучысы булып карыйсы киләме? Мин сезгә өйдә әкият уйлап табып, рәсемен ясап килергә тәкъдим итәм, сез ризамы? Балалар, сез бүген бик актив идегез. Мин сезгә барыгызга да матур көн телим.

Матур әдәбият

1. Күрсәтмә материаллар тупланмасы “Бибинур әби әкиятләре”
2. Комплексный демонстрационный материал ”Сказки бабушки Матрёны”
3. Татар балалар фольклоры./Төзүчесе Рәшит Ягъфәров.- Казан: “Раннур” нәшрияте, 1999.

Кушымта 1.

Әлеге шөгель ике өлештән торган “Бабушкины сказки” комлекты ярдәмендә үткәрелә. Беренче комлект ”Бибинур әби әкиятләре” татар, икенчесе ”Сказки бабушки Матрёны” урыс халык әкиятләреннән тора. Әкиятләр бердәм концепцияләр белән берләштерелгән, алар балаларда мөһим кыйммәтләр формалаштыра: үзара ярдәм, дуслык, ышаныч, хезмәт, йорт, кунакчыллык, акыл, игелек.

Без әлеге комплектны кулланып 2023 елны халыкара хәрәкәт тарафыннан оештырылган "Ценности будущего в традициях народной культуры" акциясе кысаларында "Бабушкины сказки" Бөтенроссия конкурсының төбәк һәм федераль этабы җиңүчесе булдык.






## МИНЕКЕ, ТИМӘ!

Гөлгенәнең уенчыклары бик күп. Тик уйнарга бер генә иптәше дә юк. Бүген әбисе аның белән уйнарга күрше малае Фәритне чакырды. Алар башта бик тату уйнадылар. Шунда матур бер уенчыкка Фәритнең дә күзе төште. Аны кулына алды. Ә Гөлгенә чырылдап кычкырып җибәрде:

— Минеке, тимә!

Аш бүлмәсеннән әбисе килеп чыкты.

— Алай ярамый, Гөлгенә! Бергә уйнагыз. Уенчыкларыңны бир, — диде ул.

Гөлгенә, теләмичә генә, бер кулы чыккан, бер аягы сынган курчакны Фәриткә сузды. Тик кулсыз курчак Фәритне тиз туйдырды. Ул икенче уенчыкка үрелде. Гөлгенә яңадан чырылдый башлады:

— Минеке, тимә! Үзем уйныйм!

Гөлгенәнең әбисе тагын килде.

— Алай ярамый, кызым. Бергә уйнагыз дим бит инде! Һай, кемгә охшап болай комсыз соң син? — диде ул.

Көтмәгәндә, Гөлгенә уенчыкларын җыеп алды да кочаклап күтәрә башлады.

— Әйдә, теге бүлмәгә чыгып уйныйк, — диде ул.

Фәрит әйбәт малай икән. Гөлгенәгә булышам дип, берничә уенчыкны ала башлады. Гөлгенәнең чырае сытылды.

— Минеке, тимә! Үзем күтәрәм!

Ул бөтен уенчыкларын да үзе генә күтәреп китәргә азапланды. Шулай кылана торгач, әнисе бүләк иткән алтын тоткалы бәләкәй чәйнеген төшереп ватты! Ватты да бик ямьсез итеп еларга да керешге. Тагы әбисе килеп җитте.

— Һай, харап иттең ич! Үзең генә уйнагач, үзең генә күтәргәч, шулай була инде ул! — диде.

### Сораулар

1. Әбисе нигә Гөлгенә белән уйнарга күрше малаен чакыра? Аның исеме ничек?
2. Фәрит Гөлгенәнең уенчыкларына кагылган саен, Гөлгенә нәрсә дип кычкыра?
3. Кыз кайсы уенчыкны вата?
4. Бу бүләк Гөлгенәгә ни өчен бик кадерле?
5. Син ничек уйлыйсың, әгәр дә Гөлгенә чәйнеген Фәриткә уйнарга биреп торган булса, чәйнек ватылыр идеме?
6. Ә син дусларыңа үзеңнең уенчыкларың белән уйнарга рөхсәт итәсеңме?
7. Син дусларың белән нинди уеннар уйнарга яратасың?
8. Синең яраткан уенчыгың бармы? Аның турында сөйлә. Сиңа аны кем бүләк итте (сатып алды)? Ул нинди төстә?

### Аралашу

Кунакчыллык кагыйдәләре ачык йөз күрсәтү, аралашучанлык турында сөйләшү. Саранлыкның тискәре сыйфат икәнен, иптәшләрең белән тату уйнаганда күңеллерәк булуын аңлату.

### Сүзлек өстендә эш

Уенчыклар, чәйнек, әби, күрше малае, саран.

## МОЁ, НЕ ТРОГАЙ!

У Гульгены очень много игрушек. Да только нет ни одного друга, с кем можно было бы вместе поиграть.

Сегодня бабушка позвала в гости соседского мальчика Фарита. Сначала дети играли очень дружно. Фариту приглянулась одна очень красивая игрушка. Стоило мальчику взять игрушку в руки, как Гульгена тут же пронзительно закричала:

— Моё, не трогай!

На шум заглянула бабушка. Она была на кухне — готовила для ребят еду.

— Так нельзя, Гульгена! Играйте дружно. Надо делиться своими игрушками, — сказала она.

Гульгена неохотно протянула Фариту игрушку с вывихнутой рукой и сломанной ногой. Однако безрукая кукла быстро надоела Фариту. Он потянулся за другой. Гульгена вновь принялась пронзительно кричать:

— Моё, не трогай! Сама буду играть!

Вновь заглянула бабушка.

— Так нельзя, внученька. Я же сказала, играйте вместе! Ой, и в кого ты только такая уродилась? — возмутилась она.

Неожиданно Гульгена собрала все игрушки в охапку и предложила Фариту перейти в другую комнату. Мальчик, желая ей помочь, начал подбирать с пола оставшиеся игрушки. Гульгена тут же скроила обиженную мину.

— Моё, не трогай! Сама подниму!

Она пыталась унести все игрушки одна. Однако, как и следовало ожидать, девочка уронила одну из своих любимых игрушек. Это был маленький чайник с позолоченной ручкой — мамин подарок! Чайник разбился. Гульгена принялась рыдать. Вновь подошла бабушка.

— Ой, ты всё испортила! Ты хотела играть одна и решила перенести сама свои игрушки — вот и результат, — сказала она.

### Вопросы

1. Почему бабушка позвала поиграть с Гульгеной соседского мальчика? Как его звали?
2. Что кричала Гульгена каждый раз, когда Фарит дотрагивался до её игрушек?
3. Какую игрушку разбила Гульгена?
4. Почему этот подарок был дорог Гульгене?
5. Как ты думаешь, разбился бы чайник, если бы Гульгена предложила Фариту поиграть с ним?
6. Скажи, ты разрешаешь друзьям играть с твоими игрушками?
7. В какие игры ты любишь играть с друзьями?
8. У тебя есть любимая игрушка? Расскажи о ней. (Кто её подарил (купил)? Какого она цвета?)

### Общение

Беседа о правилах гостеприимства: уважение, открытость, готовность к общению. Рассказать детям о том, к чему приводит жадность. Необходимо объяснить детям, как важно делиться своими игрушками с другими, тогда играть будет веселее.

### Словарная работа

Игрушки, чайник, бабушка, соседский мальчик, жадный.












Поселился солдат в селе на квартире и говорит хозяйке:
— Свари кашу!
— Да не из чего, родимый! — отвечает старуха.
— Давай топор, я из топора сварю.
«Что за диво! — думает старуха. — Дай-ка посмотрю, как он из топора кашу сварит».
И принесла топор.
Солдат положил топор в горшок, налил воды, поставил в печь и давай варить.
Варил, варил, попробовал и говорит:
— Всем бы кашица взяла, да только бы круп подсыпать.
Принесла баба круп. Солдат опять стал варить, попробовал и говорит:
— Совсем бы каша готова, только бы маслицем сдобрить*.
Принесла ему баба и масла. Сварил солдат кашу:
— Ну, старуха, давай теперь хлеба да соли, да берись за ложку: станем кашицу есть.
Похлебали вдвоём кашу, старуха и спрашивает:
— А что же, служивый, когда топор будем есть?
Солдат ткнул в топор вилкой и говорит:
— Ещё не доварился, сама завтра довари!

*_Сдобрить_ — добавить что-то в пищу для вкуса.



### Вопросы

1. О чём солдат попросил хозяйку?
2. Что хозяйка ответила на просьбу солдата?
3. Гостеприимно ли она поступила? Как ты понимаешь слово _гостеприимство_?
4. Из чего тогда солдат решил сварить кашу? Как ты думаешь, это возможно?
5. Расскажи, как солдат варил кашу. Какие продукты он выпросил у старухи?
6. Как ты понимаешь выражение «маслицем сдобрить»?
7. Получилась ли у солдата каша?
8. Поверила ли старуха, что солдат действительно сварил кашу из топора? Как ты это понимаешь?
9. Для чего солдату понадобился топор на самом деле?
10. Кто оказался умнее: солдат или хозяйка?
11. Как ты думаешь, старуха была жадная или экономная? В чём разница?
12. Удивило ли тебя название сказки?

### Общение

Во время обсуждения сказки обратите внимание детей на то, что солдату помогли находчивость и смекалка.

Обсудите с детьми, что за инструмент — топор и для чего он нужен в хозяйстве.

Организуйте игру «Съедобное — несъедобное». (Взрослый называет предметы. Дети хлопают в ладоши, когда слышат название съедобного предмета.)

Спросите детей, какие они знают каши (_гречневая, манная, перловая, овсяная_ и т. д.), как и из чего их готовят.

Предложите детям выбрать пословицу, подходящую к данной сказке:
_Старый друг лучше новых двух._
_Богатого скупого от нищего не отличишь._

Попробуйте с ребятами инсценировать сказку. Сделайте акцент на передаче интонаций старухи и солдата. (Старуха говорит то притворно плаксиво, то вкрадчиво, то осторожно, то подозрительно. Интонации солдата — громкие, открытые, чуть насмешливые.)

В конце работы предложите детям представить себя бравыми солдатами и промаршировать по кругу под весёлую ритмичную музыку.

### Словарная работа

Объясните ребятам значение слов _сдобрить, экономная_. Поговорите с детьми о том, что жадным быть плохо. Предложите подобрать синонимы к слову _жадная_. _(Скупая, прижимистая, скряга.)_

гостеприимство

**«QR код ярдәмендә татар гаиләсе һәм аның традицияләре белән танышу»**

(5-6 яшьлек балалар өчен)

*Кадырова Эльмира Айдаровна,*
*Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының “20 нче номерлы “Чыршыкай” балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү учреждениясе” тәрбияче*

Максат: QR-код ярдәмендә балаларның татар халкының гаилә традицияләре турында белемнәрен һәм күзаллауларын формалаштыру.

Бурыч:

1) балаларның гаилә, гаилә традицияләре турында белемнәрен гомумиләштерү һәм киңәйтү.

2) балаларның иҗади сәләтләрен үстерү.

3) балаларның сүзлек байлыгын активлаштыру.

4) татар халкының гаиләсенә, гаилә традицияләренә һәм мәдәниятенә мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияләү.

Җиһазлар: ноутбук, проектор, экран, телефон, колонка.

Материаллар: татар ризыклары (өчпочмак, чәк-чәк, кош теле, кыстыбый, пирог); тарату материалы (курчак малай һәм кыз, татар һәм рус костюмнары); күн беләзек, күннән эшләнелгән татар орнаменты элементлары, балалар саны буенча контейнерлар.

Дәрес барышы:

- Исәнмесез, балалар! Минем исемем Эльмира Айдаровна. Хәлләрегез ничек? *(балалар җавабы)*

Әй, балалар, монда тактада ниндидер аңлашылмаучан схема. Кем белә? Ул ничек дип атала? *(QR код).*

- Балалар, бик дөрес, бу схема QR код дип атала. Әлеге уникаль штрих кодта, кодланган мәгълүмат яшерелгән. Телефон камерасын әлеге кодка юнәлтсәң, барлык мөһим мәгълүмат телефон экранында чыгачак. Әйдәгез, балалар, телефон камерасын әлеге схемага юнәлтик тә, анда нәрсә яшерелгәнен белик!

*(Экранда чыга)*

**Исәнмесез, балалар! Минем исемем - Азат, ә минем исемем - Айсылу. Без сезне үзебезнең өебезгә чакырабыз, ә анда сезне Эльмира Айдаровна алып барачак, ул сезне безнең гаилә әгъзалары белән таныштырачак һәм аларның нәрсә белән шөгыльләнүләрен күрсәтәчәк. Ләкин безнең чакыру**

**гадәти түгел, без сезгә QR кодларны кулланып виртуаль сәяхәт тәкъдим итәбез. Сезгә бу гадәти булмаган маҗаралар ошар дип ышанып калабыз!**

- Балалар, сез барырга әзерме? *(балалар җавабы)* Алайса китәбез.

- Без сезнең белән кая килдек? Бу урын ничек атала? *(аш бүлмәсе)* Менә, балалар, QR код. Әйдәгез, карыйк әле, кем безне каршы ала икән? *(Экранда күрсәтелә)*

**Минем исемем Әлфия. Мин Азат белән Айсылуның әнисе. Мин аш бүлмәсендә һәм хәзерге вакытта татар милли ризыкларын пешерәм *(санап чыга һәм күрсәтә).* Өчпочмак, кыстыбый, чәк-чәк, кош теле, гөбәдия. Миңа гөбәдия ясарга гына калды. Сез гөбәдиянең нәрсәдән торганын беләсезме? *(җавап)***

- Балалар, әни нинди татар милли ризыкларын әзерләде? Әнигә гөбәдия ясарга булышыйк, ул нәрсәдән тора? *(җаваплар)* Әйдәгез, экранга карыйк. Экранда ашамлыклар чыгачак, безгә бары тик гөбәдия ясау өчен кирәкле ашамлыкларны гына сайлапи алырга кирәк булачак! *( ИКТ ярдәмендә уйнау)*

**Әни: Ярдәмегез өчен бик зур рәхмәт! Мин Сезнең белән танышуыма бик шат идем.**

- Яхшы, балалар. Без әнигә булыштык, алга барабыз. Без кая килдек? *(бүлмәгә)* ә монда кем икәнен белергә телисезме? *(җавап)* Менә QR код. Әйдәгез карыйк! *(Экранда күрсәтелә)*

**Исәнмесез, балалар! Минем исемем Нәҗия апа. Мин Азат белән Айсылуның әбисе. Мин тегәргә һәм чигәргә яратам, чигү белән сөлге, япма, юрган һәм киемнәр бизим.**

- Балалар, сез татар костюмының нинди элементларын беләсез? *(җаваплар)* Мин хәзер сезне уйнарга чакырам. Әйдәгез, курчак Азат белән Айсылуны татар костюмнарына киендерик. Аның өчен ике командага бүленәбез: кызлар командасына һәм малай командасына. Кызлар командасы Айсылу кызын, ә малайлар командасы Азатны киендерәчәк. Өстәлдә татар костюмнары гына түгел, рус костюмнары да бар, шуңа күрә игътибарлы булыгыз! *(балалар курчакларны киендерәләр)*

Балалар, әйдәгез бераз читкә китеп, карыйк, ничек килеп чыкты икән! Афәрин! Бик матур булган!

**Әби: Әй, балалар, бигрәк уңганнар икәнсез, костюмнарны дөрес сайлагансыз!**

- Нинди кызык булды, сәяхәтебезне дәвам итәбезме? *(җаваплар)* Алайса, киттек. Менә QR код , бу бүлмәдә безне кем каршы ала икән? *(экранда күрсәтелә)*

**Исәнмесез, балалар! Минем исемем Мансур абый. Мин Азат һәм Айсылу бабасы. Ай, балалар, сез миңа озак килдегез, әнидә булдыгыз, әбидә**

**булдыгыз, ә мин сезне бик көттем. Мин сезгә үземнең татар музыка коралларын күрсәтермен.** ***(Музыка кораллары белән таныштыра).*** **Бу - гармун. Әйдәгез, сезнең белән бергә ял итик, мин сезгә татар көйен уйныйм, Эльмира Айдаровна сезгә татар биюендә нинди хәрәкәтләр кулланылганын күрсәтәчәк, ә сез аның артыннан кабатлагыз!** ***(Балалар биилә*р**)**

**Бабай: Рәхмәт, балалар. Мине шатландырдыгыз!**

- Балалар, без сезнең белән икенче бүлмәгә килдек. Менә QR код. Әйдәгез, безне кем каршы ала икән. *(Экранда күрсәтелә)*

**Исәнмесез, балалар! Минем исемем Алмаз. Мин Азат һәм Айсылуның этисе. Мин күннән итек, сумка ясыйм һәм мозаика белән бизим. Элек кешеләр барысын да үзләре эшләгәннәр, тукымадан кием, күннән аяк киеме тегкәннәр, ә үз куллары белән ясалган бизәнү әйберләре иң кыйммәтлесе дип саналган.**

- Балалар, мин сезгә бүген күн мозаикасы остасы булырга тәкъдим итәм. Әйдәгез, беләзекләр ясыйк. Моның өчен, урындыкларга утырыгыз, сезнең алдыгызда кәрзиннәр. Монда һәрберегезгә күннән ясалган беләзек һәм татар орнаменты элементлары бар. Үрнәк элементларын алыгыз, беләзеккә куегыз, әгәр сезгә ошаса, бизәк элементының саклагыч катламын куптарып, ябыштырыгыз.

**Әти: Бу беләзекләрне сез безнең гаилә истәлегенә үзегез дә калдыра аласыз! Сау булыгыз!**

- Балалар, нинди матур беләзекләр ясагансыз! Сезгә бүгенге сәяхәт ошадымы, сәяхәт вакытында аеруча нәрсә кызык булды? *(балалар җавабы)*

- Балалар, сәяхәт итәргә безгә нинди технология ярдәм итте? *(балалар җавабы)*

Минем белән бергә сәяхәт иткәнегез өчен зур рәхмәт!

**"Казан Кремль буенча сәяхәт"**
Балаларны татар теленә
өйрәтү буенча комплекслы дәрес
(Дәрес эшчәнлеген оештыру)
Өлкән төркем балалары өчен

*Авторлар:*
*Әхмәтҗанова Мәдинә Мәскутовна*
*1квалификация категория тәрбиячесе*
*Галиева Венера Ильдаровна*
*1 квалификация категория тәрбиячесе*
*Биктагирова Люция Гумаровна*
*1квалификация категория тәрбиячесе*

**Программаның эчтәлеге**

1. Балаларны диалоглар төзәргә, җөмләләр төзәргә өйрәтү, схема буенча сорауларга җавап бирү, сүзләрне дөрес әйтү;
2. Балаларның белемнәрен үстерү, шәһәрнең истәлекле урыннары белән таныштыру;
3. Туган якка мәхәббәт тәрбияләү.

**Сүзлек өстендә эш, сүзлек запасын баету:**

- шәһәр(город);
- манара;
- шәһәрнең истәлекле урыннары;
- бина;
- кунаклар.

**Сүзлек запасын активлаштыру:**

- яшел;
- ак;
- кызыл;
- зәңгәр;
- көрән;
- ярым ай;
- сәгать.

**Җиһазлау, күрсәтү әсбаплары:**

1. Магнитофон;
2. Фланеграф һәм киселгән рәсемнәр биналарның сүрәте белән;

3. Казан Кремльнең схема-картасы;
4. Фото рәсемнәр Кремльнең истәлекле урыннары белән;
5. Бинаның силуэтлы контурлары;
6. Схема;
7. Удостоверениялар, медальләр.

**Алдан әзерлек эш:**

Мини-музейга сәяхәт, шәһәрнең истәлекле урыннары белән танышу, рәсемнәр карау, Казан турында сөйләшү, «Казан шәһәре буенча сәяхәт» китабы белән танышу.

**Дәрес барышы:**

(Роберт Ракыйпов сүзләренә “Мин яратам сине Татарстан” җыры әкрен генә яңгырый, балалар түгәрәккә басалар)

Алия: Исәнмесез, балалар. Без гаиләбез белән каникулларда Республикабызның башкаласы Казан шәһәренә Казан Кремленә барырга булдык.

Тәрбияче: Балалар, Алиянең экскурсовод буласы килә. Һәм ул гаиләсе белән Казан шәһәренә экскурсиягә җыена. Ул бездән ярдәм сорый. Казан шәһәре белән таныштырырга һәм шәһәр турында сөйләргә.

Алия: Балалар, сез миңа ярдәм итәсезме?

Балалар: Эйе, булышабыз, ярдәм итәбез.

Тәрбияче: Балалар, искә төшерегез, без кайсы Республикада яшибез?

Балалар: Татарстан Республикасында.

Тәрбияче: Әйе, дөрес. Татарстанның башкаласы нинди шәһәр?

Балалар: Казан шәһәре.

Тәрбияче: Бик дөрес, Татарстанның башкаласы – Казан шәһәре. Ул бик матур, бик борыңгы шәһәр. Анда истәлекле урыннар бик күп. Башкалабызга Рәсәйнең төрле якларыннан, чит илләрдән дә куп туристлар һәм кунаклар килә. Кунакларны Казан шәҺәре белән таныштыру өчен, безгә күп экскурсоводлар кирәк булачак, һәм без сезнең белән кунакларга борыңгы, матур шәһәребез турында сөйләр өчен «Ак чәчәк» исемле № 15 балалар бакчасында экскурсоводлар мәктәбен ачабыз. Бу мәктәпне тәмамларга безгә күп көч һәм белем тупларга кирәк. Һәм Алияне дә бу мәктәбкә алабыз. Әйтегез әле, көчегез җитәчәкме белем алыр өчен?

Балалар: Әйе!

Тәрбияче: Күрсәтегез әле! Әйдәгез бергәләп: 1, 2, 3 бездә куәт, бездә көч; 1, 2, 3 бездә белем, бездә көч.

Тәрбияче: Мин күрәм, сез әзер. Әйдәгез, дәресне девиз белән башлыйбыз:

- **Девиз**

Бергә без җинәрбез, авыр юлларны үтәрбез.
Күпне белербез, белемле булырбыз.
Тәрбияче: Беренче биремгә күчәбез.

- **1 бирем: Дидактик уен “Картадагы Кремль территориясендәге истәлекле биналарны дөрес урнаштыр”**

Тәрбияче: Балалар сезнең алда тутырылмаган Кремль картасы һәм биналарның контурлары. Кремль территориясендәге истәлекле биналарны дөрес урнаштырырга кирәк (балаларнын үзлектән эшләре, карта-схема буенча эшне тикшерү).

Тәрбияче: Булдыклы икәнсез, минем яшь экскурсоводларым, беренче биремне җиңеп чыктыгыз. Икенче биремгә күчәбез.

- **2 бирем: Дидактик уен “Бинанын исемен әйт”**

Тәрбияче: Хөрмәтле булачак экскурсоводлар, үзегез теләгән фоторәсемне сайлап алыгыз да, алдыгызга бөркетеп куегыз һәм түгәрәккә басыгыз. Турист кем булачагын сайлагыз. Әйдәгез балалар, туристка булышабыз, биналарның исемнәрен дөрес әйтик, чөнки турист бина исемнәрен белми.

- **Уен: « Түбәтәй»**

(Сүзләрен әйтеп, түбәтәй түгәрәк буенча кулдан
кулга бирелә һәм бинанынисеме әйтелә)

Түп-түп түбәтәй, түбәтәем укалы,
Чиккән матур түбәтәең, менә кемдә тукталды.
(балалар җавабы: бу Сөембикә манарасы; бу Спас манарасы; бу Кул-Шәриф мәчете; бу Благовещенск соборы; бу Рәис резиденциясы).

Тәрбияче: Булдыклы икәнсез, балалар. Мин уйлыйм турист сезнең җавапларыгыз белән канәгать булыр. Балалар! Мәктәптә бер хәл ачыкланды. Туристлар өчен фоторәсемнәр әзерләнгән иде, кемдер аларны ертып ташлаган. Бу фоторәсемнәрне реставрацияләргә кирәк.

- **3 бирем: Дидактик уен “”Фоторәсемнәрне кисәкләрдән җый”**

Тәрбияче: Сезгә уйларга кирәк: кем турист була, ә кем – экскурсовод һәм бергәләп фоторәсемнәрне бергәләп җыярга. Җыйгач, турист рәсем буенча сораулар әзерли, ә экскурсовод җавапларын бирә. Аннары киресенчә: турист бина турында сөйли, экскурсовод нинди бина икәнен әйтергә тиеш (балалар җаваплары: Турист - Бу манараның исеме ничек? Экскурсовод - Бу Спас манарасы. Турист - Ул нинди төстә? Экскурсовод - Ак төстә. Турист - Нәрсәдән төзелгән? Экскурсовод - Кирпичтән. Турист - Бу мәчетнең исеме ничек? Экскурсовод - Бу Кул-Шәриф мәчете. Турист - Ул нинди төстә? Экскурсовод – Ак төстә. Турист - Мәчетнең манарасын нәрсә бизи? Экскурсовод – Ярымай. Турист - Бина көрән төстә. Җиде яруслы. Манара өстен ярым ай бизи. Бу манараның исеме ничек? Экскурсовод – Сөембикә

манарасы. Турист - Бу Казан шәһәрендә иң мөһим бина. Бу бинада Татарстан Республикасының иң баш кешесе утыра. Бинаның түбәсендә Татарстан флагы. Бу нинди бина? Татарстан флагы ничә Һәм нинди төстә тора? Бу президент резеденциясы. Экскурсовод – Флаг өч төстән тора: яшел, ак, кызыл).

Тәрбияче: Булдыклы икәнсез! Булыштыгыз! Ә Татарстан Республикасының Рәисе – кем ул?

Балалар: Рустам Нургалиевич Минниханов

Тәрбияче: Дөрес җавап бирдегез, әйе Рәисебезнен исеме - Рустам Нургалиевич Минниханов. Ә хәзер, балалар, безнең эксурсоводлар мәктәбендә имтихан. Имтихан биргәч сез удостоверениялар алырсыз.

- **<u>Имтихан: Дидактик уен “Сораулар буенча рәсем яса”</u>**

Тәрбияче: Балалар, сезнең алда карточкалар. Сулдан уңга һәрбер буш карточкада турист биргән сораугa рәсем ясарга һәм саннар язарга кирәк:

1. Сөембикә манарасы ничә ярустан тора?
2. Спас манарасын нәрсә бизи?
3. Татарстан флагы ничә төстән тора?
4. КАЗАН сүзе рус теленә тәрҗемә иткәндә нәрсәне аңлата?

(Җаваплар: җиде; сәгать; өч; котел)

Тәрбияче: Афәрин, балалар!

- **<u>Дидактик уен “Рәсемнәрне җый”</u>**

Тәрбияче: Әйдәгез, истәлеккә туристка рәсемнәр бүләк итәбез. Рәсемнәр бүләк итәр өчен, ике командага бүленеп, аларны җыярга кирэк булыр (балалар ике командага бүленә. Беренче төркем җиде каттан торган манараны җыя, икенче төркем сәгәть бизи торган бинаны җыя.

Тәрбияче: Балалар, без бөтен биремнәргә дөрес җавап бирдек, уңышлы гына имтиханнарны бирдек. Белемнәрне ныгыттык һәм рәсемнәрне туристка бүләк иттек. Сезгә яхшы укыган өчен удостоверениялар һәм медальләр тапшырам. Әйдәгез, бергәләп девиз белән дәресне тәмамлыйбыз.

- **<u>Девиз</u>**

Бергә без җиндек, авыр юлларны үттек.
Күпне белде, белемле булдык.

Тәрбияче: Мин балалар, сезгә ышанам, бу мәктәпне тәмамлагач, сез Татарстан Республикасына һәм Казанга килгән кунакларны каршы алып, аларны шәһәрнең истәлекле урыннары белән таныштырырсыз. Алия, без сиңа булыштык мы? Алия: Әйе, минем хәзер дипломым да бар! Зур рәхмәт сезгә балалар! Белем өчен рэхмәт. Минем уйлавымча, мин гаиләбез өчен экскурсовод ролен үтәрмен һәм минем экскурсиям һәркемгә ошар.

Тәрбияче: Дәрес (белем бирү эшчәнлеге) шуның белән тамам. Хәерле юл телим сезгә, минем яшь экскурсоводларым.

Роберт Ракыйпов сүзләренә
«Мин яратам сине Татарстан» җыры башкарыла.

**Кулланыла торган әдәбият исемлеге:**


1. Гафаров И.А. Тарих битләрен ачып.Казан: Каз.пед. ун-т,1996 елгы - 77 б.
2. Казан. Елларны бәйләүче җеп / Л. И. Девятых һ. б. - Казан: Титул, 2000. - 279 б.
3. Халитов Н.Х. Казанның XVIII XIX гасыр башы архитектура һәйкәлләре - М.: Стройиздат, 1991. - 191 б.
4. Ханзафаров Н.Г. Сөембикә манарасы тарих һәм мифология яктылыгында // Идел. - 1990. - №9. б.12-1б.


**«Минем гаиләм»**

Мәктәпкә әзерлек төркемендә интеграль шөгыль


*Кабирова Эльза Альфрит кызы,*
*Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Осиново авылының “Катнаш төрдәге 25нче номерлы “Аленушка” балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү учреждениесе тәрбиячесе*


**Максатлар:** балаларның гаилә турында, бергә яшәүче кешеләр буларак, күзаллауларын киңәйтү; гаилә әгъзаларына мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияләү.
**Бурычлар:**
Белем бирү:
-Гаилә төшенчәсен, гаилә әгъзаларын бер-берсенә ярдәм итүче һәм кайгыртучы кешеләр буларак күзаллауны формалаштыру;
- Балаларның сүзлек байлыгын арттыру;
- Олыларның сорауларына тулы җөмләләр белән җавап бирергә, гади һәм киң таралган конструкцияләр төзергә өйрәтү;
Үстерү:
-Бәйләнешле, диалогик сөйләм, хәтер, игътибар, танып белү кызыксынуы, логик фикерләүне үстерүне дәвам итү;
- Гаилә тарихы, гаилә традицияләре, шәҗәрә белән кызыксынуны үстерү.
Тәрбия :

- Гаиләләре өчен горурлык хисе тәрбияләү һәм алар турында кайгырту теләге үстерү.

**Җиһазлау:** гаилә фотолары, шәҗәрә агачы, рәсемнәр: әни, әти, бабай ,әби, балалар.Ромашка чәчәкләре ясау өчен төсле кәгазьләр,кайчы,җилем,картон,пумала.

**Эшчәнлек барышы**

Тәрбияче балалар белән түгәрәк ясап басалар.

**Тәрбияче:**Әйдәгез әле,балалар, бер-беребезне сәламлик!

Хәерле көн!

Хәерле көн, миңа да!

Хәерле көн, сиңа да!

Хәерле көн һәммәбезгә дә!

**Тәрбияче:**Балалар карагыз әле монда нинди матур агач!Бу агач ,гади агач түгел.Бу минем нәсел шәҗәрәм. (Фотоларга игътибар итеп) сез бу фотоларда кемнедер таныдыгызмы? Әйе, бу мин. Сез мине таныдыгыз. Ә сез бу кешеләрне беләсезме? Әлбәттә, юк. Бу кешеләр сезгә таныш түгел, алар сезнең өчен чит кешеләр. Ләкин минем өчен түгел. Минем өчен бу иң кадерле кешеләр. Бу минем гаилә әгъзалары. Бу безнең зур һәм тату гаиләбез. Балалар, сез гаиләнең нәрсә икәнен ничек аңлыйсыз? (Балалар җаваплары)Гаилә-кеше өчен иң кадерлесе. Гаилә әгъзалары бер-берсен яраталар, бер-берсе турында кайгырталар, якыннарын һәм кадерлеләрен рәнҗетмәс өчен барысын да эшләргә тырышалар.

**Тәрбияче:** Ә кемнәр соң гаилә әгъзалары?

**Балалар:** Әни, әти, әби, бабай.

**Тәрбияче:** Ә гаиләнең барлык әгъзаларын да туганнар дип атыйлар, бу бер-берсенә туган кешеләр: апалар, абыйлар, бабайлар ,әбиләр, әтиләр, әниләр.Балалар, мин сезне гаиләмнең барлык әгъзалары белән таныштырдым, ә үзенең гаиләсе турында кем сөйләр?

**(Гаиләләре турында балалар сөйлиләр)**

**Тәрбияче:** Күрәм балалар, сез гаиләгез турында күп сөйли аласыз. Онытмагыз: әниләр, әтиләр, абыйлар, апалар, бабайлар ,абиләр – сезнең якын туганнарыгыз , гаиләгез. Ә хәзер “Кем артык?”уенын уйнап алырга тәкъдим итәсем килә сезгә.

**“Кем артык?” дидактик уены**

Әни, күрше ,әби, апа

Әби, дус кыз, апа, әни

Сеңел,кибетче,абый,әти

Укытучы, әти, абый, бабай.

**Тәрбияче :**Афәрин ,дуслар,булдырдыгыз!Иң электән кешеләр гаиләләрен хөрмәт иткәннәр, саклаганнар, әтигә һәм әнигә карата ярату һәм хөрмәт белән караганнар. Шуңа күрә безгә бик күп мәкаль-әйтемнәр килеп ирешкән. Сез гаиләгә карата нинди мәкаль-әйтемнәр беләсез?
Гаилә — гомер чишмәсе.
Әткәй — шикәр, әнкәй — бал.
Гаилә — ил терәге.
Ата-ананы тыңлаган — адәм булган, тыңламаган — әрәм булган.
Ана җылысы — кояш җылысы.
Гаилә- бәхет ачкычы.
Өйнең яме ана белән.
Кош – канаты белән, гаилә – дуслыгы белән көчле.
**Тәрбияче:**Әйе,бик дөрес.Балалар ,бик күп мәкаль-әйтемнәр беләсез икән,афәрин!

**Физминутка**

Күрсәт әле үскәнем, әни ничек бии?
Менә шулай,менә шулай бии.
Күрсәт әле үскәнем, әти ничек машина йөртә?
Менә шулай,менә шулай йөртә.
Күрсәт әле үскәнем, әби ничек бәйли?
Менә шулай,менә шулай бәйли..
Күрсәт әле үскәнем, кошлар ничек очалар?
Менә шулай,менә шулай очалар ..
Күрсәт әле үскәнем, поезд ничек йөри?
Менә шулай,менә шулай йөри..
**Тәрбияче:** Булдырдыгыз балалар!Гаиләнең барлык әгъзалары бер-берсе белән күзгә күренми торган җепләр кебек туганлык мөнәсәбәтләре белән бәйле. Хәзер без сезнең гаиләдә кемгә кем булуын белүегезне тикшерәчәкбез. Түгәрәккә басыгыз. Мин тупны ыргытачакмын һәм сорау бирәчәкмен, ә сез тупны миңа кире ыргытасыз һәм сорауга җавап бирәсез.

**“Кемгә-кем?” уены**

Мин сиңа Әни, димәк син миңа (Улым, кызым).
Мин сиңа әби – син миңа (онык, оныкчык).
Мин синең сеңлең, син миңа (абый, апа).
Мин синең әтиең, син миңа (кызым,улым).
Мин сиңа бабай – син миңа (онык, оныкчык).
Син миңа онык- мин сиңа(дәү әни,дәү әти)

**Тәрбияче**: Бик яхшы, сез туганлык мөнәсәбәтләрен әйбәт беләсез икән! Балалар, хәтта “Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көне” дип аталган бәйрәм дә бар. Рәсәйдә аны җәй көне -8 июльдә бәйрәм итәләр. Бәйрәмнең символы - ромашка чәчәге. Мин сезгә үз кулларыгыз белән шундый чәчәк ясарга һәм сез бик яраткан кешегә бүләк итәргә тәкъдим итәм.

**(Ромашка чәчәге ясау)**

**Тәрбияче:** Бик яхшы!Нинди матур ромашка чәчәкләре ясагансыз! Ә мин, үз чиратымда, сезнең нык, тату, яратучан гаиләгез булуын телим. Туганнарыгыз сезгә һәрвакыт ярдәм итәрләр, кабул итәрләр һәм аңларлар.

**Чыганаклар**

1.https://salavatkupere.com/news/uennar/

## «Шатлык өләшүче дуслар»

*Тәхаветдинова Рәмзия Рәисовна,*
*Тататарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «10 нчы «Йолдызлык» балалар бакчасы»муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең югары квалификацион категорияле тәрбиячесе*

Максат: Фребель бүләкләрен кулланып проблемалы ситуацияләрне хәл итү барышында балаларның интеллектуаль сәләтләрен үстерү.

Бурычлар:

Әйләнә-тирәдәге обьктлар турында беренче күзаллауларынбулдыру, танып белү эшчәнлеген формалаштыру.

Сенсор күнекмәләрен, балаларның сөйләм телен, диалогик сөйләмне, кул чуклары эшчәнлеген үстерү; иҗади күзаллау, фикерләүләрен киңәйтү.

Балаларның үз фикерләрен әйтә белү, үзара хезмәттәшлек итү күнекмәләренкамилләштерү.

Әйләнә-тирәдәгеләрнең кәефен эмоциональ кичерешләрен тоя белү күнекмәләрен үстерү, игелекле хисләр тәрбияләү.

Кирәкле әсбаплар: Фребель Бүләкләре № 1,3, 4, 5,6,7,8,9,10,11модульләре, кечкенә ковролиннар, “тылсымлы түбәтәй”кулланмасы, интерактив такта, төрле эмоцияләрне (уңай һәм кире) чагылдырган карточкалар, №1 Бүләк өчен схемалар, төрле эмоцияләрне чагылдырган ромашка таҗы.

Дәрес барышы

1.-Балалар, сезнең кәефегез ничек? *(балаларның җаваплары)*

Ә кәеф кайчан яхшы була?

Мин хәзер сезне кәефне күтәрү өчен бергәләшеп өстәл артына “Тылсымлы түбәтәй уенын уйнарга чакырам. (түбәтәй формасында өсте замок белән ачыла -ябыла торган, ян бортларына балалар кулы сыярлык уем (отверстие) ясалган түгәрәккә кулларын тыгып бер-берсенең кулларын тоталар, кем кулын токаннарын әйтәләр, дөреслеген замокны ачыпкарап тикшерәләр) 1-2 тапкыр уйнала. Икенче тапкыр уйнаганда урыннарын алмашалар.

-Бер-беребезнең кәефен күтәрдек. Карагыз әле балалар, өстәл артларында күңелсез йөзләр төшерелгән карточкалар, алар сездән ярдәм көтәләр. Әйдәгез, аларның ник кәефләре булмавын ачыклыйк та аларга яхшылык эшлик, кәефләрен күтәрик. Бар да гадел булсын өчен кайсы өстәл янына барасын ромашка таҗларын ярдәмендә хәл итик. Таҗларның икенче ягында шул йөзләр төшерелгән. (Балалар бер ромашка таҗын алып аның икенче ягына нинди йөз төшерелгәнен карап, шул йөз төшерелгән карточка куелган өстәл янына бирем үтәргә баралар)

2.-Бу тажда нинди кәеф ясалган, әйдәгез шул өстәл янына барыйк. (курку) –Нәрсәдән курыккан икән бу йөз?

-Еланнан?

- Бу бит куркыныч елан түгел, уйнап күрсәтик, кәефен күтәрик.(*Шнурга Фребель Бүләкләренең №11кулланып түгәрәк буенча йөртеп һәр бала төрле геометрик фигураларны саплый*)

-Мин елан,елан,елан

Шуышам да шуышам

Койрыгым буласыңмы?

Әлбәттә инде булам. Мин сары,.. шар(куб, цилиндр) булам –дип шнурны икенче балага бирә, икенчесе шулай ук дәвам итә.

-Нинди төсле-төсле матур елан килеп чыкты.

-Әлеге йөзнең кәефе ниндигә үзгәрде (*бәхетле йөзне кую*)

3. Киләсе тажны сайлыйбыз Нинди тажны сайладын Эмир? (*елау*)

- Ничек уйлыйсыз, ни өчен шундый кәеф икән? (өстәлдә “Өч аю” экиятеннән кыз ясаган тәртипсез күренеш.Нинди тәртипсезлек икәнен балалар әйтәләр.

Әйдәгез Машага бүлмәләрне тәртипкә китерегә ярдәм итик. Аш бүлмәсен кызлар,йокы бүлмәсен малайлар тәртипкә китерсен. (*яисә үзләренә сайлату*) (Фребель Бүләкләренең №3,4,5,6, 7,8,9,10 кулланыла)

Әлеге йөзнең кәефе ниндигә үзгәрде (*шатлыклы йөзгә алыштыру*)

- Ул сезгә бик рәхмәтле.

4.Әйдәгез киләсе таҗны сайлыйк. Айлин син алып кара, нинди таҗны алдың? (*борчылу*)

-Ни өчен уйга калган бу йөз, ничек уйлыйсыз(*яз табигатен чагылдырган күренеш, әмма анда нindидер детальләр җитеп бетми, шуларны тулыландырырга кирәк*)

Нинди сәерлек күрәсез бу күренештә?

- Кояшның нурлары юк, умырзаяның таҗы, сыерчык оясының тишеге, агачның бөреләре, күлдәвекләр юк.( *Балалар җавабын тыңлау*)

Ничек тулыландырып була бу күренешне (балаларның җаваплары) (Фребель Бүләкләренең №7, 8, 9, 10 кулланыла)

-Нинди матур язгы күренеш килеп чыкты, карагыз әле уйланып торган йөз елмайды.

5. Нинди йөз сайланмады? (*Уйлану*)

Сез ничек уйлыйсыз, бу йомшак тупларга карагач нәрсә дип уйлый икен ул?(*балаларның җаваплары*)

-Бу йомшак туплар белән ничек уйнап була инде дип уйлыйдыр мөгаен?

-Схемаларга карап уйнап үзегезгә ошаган төстәге шарларны алып күрсәтәбезме? (*электрон тактага схемалар чыгару,чиратлаштырып, шул хәрәкәтләрне әйтеп уйнап күрсәтәләр*)

Алга-артка эчендә-тышында
Уңга-сулга туп бар-туп юк
Аска-өскә шуыша-сикерә

- Карагыз әле балалар, бу йөз дә нindигә үзгәрде?( *күз кысып рәхмәт әйтү карточкасын кую*)

-Балалар, сез бүген нинди яхшылыклар эшләдегез.?

Шулкадәр яхшылык эшләгәч, үзегезнең кәефегез ничек?

Яхшы кәеф һәрчак яхшы эшләрдән тора, шуны онытмагыз, балалар.

## **«Әниемә – җырларым!»**

мәктәпкә әзерлек төркемендә бәйрәм сценариясе

*Гарипова Лилия Сабир кызы,*
*Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының*
*“Гомуми төрдәге №23 “Золотой колосок” балалар бакчасы”*
*муниципаль мәктәпкәчә белем бирү бюджет учреждениесе тәрбияче*

Музыка яңгыравына балалар залга кереп басалар.
Алып баручы Исәнмесез, кадерле кунаклар. Сезне “Алтын башак” балалары сәламли!
Мәликә Карап тормый ара еракка,
Дуслар килә безгә кунакка!
Дуслык - безнең куңел көзгесе,
Дуслык - безнең тормыш бизәге.
Бәйрәмсез бик куңелсез бит.
Куңелсездер сезгә дә.
Бәйрәмнәр кирәк безгә дә.
Бәйрәмнәр кирәк сезгә дә.
Кирәк һәммәбезгә дә!
Без сезне куптэн котэбез, сезнен хэрберегез очен - жылы сузебез, ачык йөзебез!
Алып баручы Әйтегез әле, хәзер елның кайсы фасылы? Көз. Ә яфраклар нинди төстә? Сары. Менә хәзер яфраклар турында җыр тыңлап узыгыз.
Җыр “Яфрак бәйрәме”
Менә шушындый матур да, җилле дә, салкын да, алтын да көз аенда бер бәйрәм бар. Ул әниләр бәйрәме. Без бүген, әниләрне хөрмәтләп, зурлап, аларга багышланган кичә әзерләдек. Кичәбезне “Әниемә - җырларым” дип атадык. Рәхим итеп карагыз, рәхәтләнеп ял итегез.
Әни, ана, әнкәй, әнием... Нинди җанны иркәли торган ягымлы, нәфис сүз. Бу сүзне без көнгә ничә мәртәбә әйтәбез икән.
Әни...Аның турында никадәр матур җырлар, шигырьләр, хикәяләр иҗат ителгән. Һәрберсендә ана образының бөеклеге сурәтләнгән. Әни безне дөньяга китерә, бишек җырлары җырлап йоклата. Безнең телебез дә әни диеп ачылган бит. Әни – әни инде ул. Серләреңне дә, борчуларыңны да әни белән уртаклашасың. Әни берәр җылы сүз әйтсә, күңелләрең күтәрелеп, рәхәт булып китә. Ә инде йомшак кулы белән сыйпап та куйсамы...Синнән дә бәхетле кеше юк бу дөньяда! Сез балалар бакчасыннан кайтканда, өйләр җыештырылган, ашарга пешкән, керләр юып үтүкләнгән була. Әниләр гөлләр үстерергә дә яраталар, чәчәк атканга куаналар. Әни белән рәхәт! Әниләргә хөрмәт һәм дан! Балалар, әниләрегезнең сүзләрен тыңлагыз, кушкан йомышларын үтәгез, тырыш булыгыз. Һәркайсыгызның әнисе сезгә “Рәхмәт, балакаем!” дип әйтә алсын.
Җыр “Рәхмәт, әнием”
Алып баручы Балалар, сез төркемегездә дус, тату яшисез, уйнысыз, рәсем ясыйсыз, җырлыйсыз, мультфильмнар карыйсыз, төрле бәйрәмнәрдә катнашасыз. Әти – әниләрегез сезне балалар бакчасына йөртә, чөнки монда сез

уйнап кына калмыйсыз, тормыш серләренә өйрәнәсез. сез көн саен ниндидер яңа мәгълүмат аласыз, көн саен үсәсез. Олыларны хөрмәт итәргә өйрәнәсез.
Җыр “Әбием”
Алып баручы Вальс! Вальс!
Яңгырый киң залда.
Вальс! Вальс!-
Канат ул һәр җанга.
Вальс! Вальс!-
Кушылыйк без аңа!
Вальс залда, киң залда
Вальс – һәркайда!
Балалар башкаруында Вальс
Алып баручы Ризаэтдин Фәхретдин “Алтыннан бәһале, оҗмах нигъмәтләреннән кадерле булган нәрсә – тәрбияле баладыр”, дигән. Тәрбияле бала – ул синең горурлыгың, өметең, киләчәгең. Бала тәрбияне ата - анасыннан күреп үсә, олылар бала өчен үрнәк өлгесе булып тора. Бала әти – әнисенең аңа ягымлы карашын, җылы мөнәсәбәтен, үзенең гел кирәк икәнен тоеп үссә, ул кешеләргә карата да дус, тату мөнәсәбәттә булачак, ә иң мөһиме, җәмгыятькә файдалы кеше булып үсәчәк! Балалар, ә сез өйдә әниләрегезгә булышасызмы? Әйе. (тузаннар сөртәм, уенчыкларымны алып куям, чынаягымны юам, энемне карашам, өй җыештырам) Ә сез ничек яулыклар юасыз, күрсәтегез әле.
Җыр “Без яулыклар юабыз”
Алып баручы Бүген безнең бакчабызга безнең бакчага йөргән укучы балаларыбыз килде. Алар хәзер сезгә үзләренең һөнәрләрен күрсәтерләр.
10 нчы гимназия укучылары Рәмилә Валиева скрипкада һәм синтезаторда уйный
Ева Корнева баянда уйный
5 нче татар гимназиясе укучысы Әмир татарча бию
Алып баручы Безнең бакчага йөрүче балалар бик бәхетле, алар монда күп кенә һөнәрләргә өйрәнәләр: җырларга, биергә, шигырь сөйләргә. Нәфис сүз аша татар теленең нинди бай, моңлы, аһаңле икәненә төшенәләр.
Балалар шигырьләр сөйли (Мәликә)
Әниләргә сөю бүләк итик
Энҗе Әхмәтҗанова сүзләре
Әниләргә атап шигырь язак,
Җырлар җырласак та аз сыман.
Әниемнең олы йөрәгенә
Дөньяның бар җылысы сыйган.

Чәчәк бүләк итсәм, әни белән
Чәчәк тә тиңләшмәс, тиз сулыр.
Әнинең нурлы, матур күзләре
Бары изгелек белән тулы.
Әниләргә сөю бүләк итик,
Назлы сүзләр белән иркәлик.
Күңелләре шатлыкка уралсын
Алар безгә бик тә кирәк бит!
Әнием (Инзилэ)
Ренат Харис сүзләре
Әнием минем матур,
Күзләре якты, көләч.
Шундый күңелле була,
Ул өйгә кайтып кергәч.
Мин елышам әнигә,
Әни миңа елыша.
Битләре аның кайнар,
Ә куллары йоп – йомшак.
Конфет та кирәк түгел,
Кирәк түгел курчак та,
Чөнки мин әниемне
Алдым инде кочаклап!
Уен “Чума үрдәк, чума каз”
Алып баручы Без әниләр турында мәкальләр беләбез. Менә тыңлап карагыз әле.
1.Тән биргән дә әни,
Сөт биргән дә әни.
Көй биргән дә әни
Тел биргән дә әни.
2.Әни – шәфкать диңгезе.
3.Әткәй – шикәр, әнкәй – бал.
4.Әнкәм йорты – алтын бишек.
5.Туган ана бер,Туган Ватан бер.
6.Алтмышка җитсен бала.,
Ана өчен һаман да бала.
7.Суга бата башлагач, бабай да “Әнием! дип кычкырган.
8. Өйнең яме –әни белән.
Алып баручы  Менә нинди акыллы һәм  мәгънәле татар мәкальләре!
Бу бик яхшы биюче,

Бу бик яхшы биюче.
Аның биюе яхшы
Аннан үрнәк алыгыз.

Бие әле, бие әле,
Биегәнең юк әле.
Сине матур бии, диләр,
Биетеп карыйк әле!

5 нче татар гимназиясен хореография укытучысы Ләйсән Исмагиловна башкаруында

Бию

Алып баручыЙөрәгемнең иң түрендә,
Иң кадерле әнием.
Яхшылыкта, яктылыкта
Әниемә тиң илем.

Җыр “Әни кирәк”

Алып баручы Хөрмәтле кунаклар, бу балалар арасында төрле милләт балалары бар, алар төрле: кемдер сабыр, түземле, кемдер җитез, кемдер өлгер, кемдер остарак, кемдер шук, ләкин алар барысы да итагатьле, инсафлы балалар. Без, тәрбиячеләр, безнең бакчага йөрүче балаларның эти – әниләре белән кулга – кул тотынышып эшлибез, шулай булса гына, без тәрбияле, әхлаклы балалар үстерә алачакбыз, чөнки әхлаксызлык - хәзерге җәмгыятьне бик борчыган мәсьәлә. “Әнием, этием!” дип торган балалар үстерергә язсын барыбызга да.

Алып баручы
Җитәкләшеп без дә, дуслар,
Биеп алыйк, әйдәле!
Котлы булсын, гөрләп торсын
Әниләрнең бәйрәме!

Балалар катнашында татарча бию “Әйдә”

Алып баручы Кадерле балалар, без нинди матур җирдә – Татарстанда яшибез. Татарстан - безнең туган ягыбыз! Ә Яшел Үзәнебез нинди гүзәл безнең, яраткан шәһәребезгә 90 ел!

Җыр “Гүзәл туган ягыбыз”

Алып баручы Хөрмәтле кунаклар, бүгенге бәйрәм кичәсе тәмам. Безгә илтифат күрсәтеп бәйрәмебезгә килгән һәм аны ямьләндереп җибәргәнегез өчен зур рәхмәтләребезне әйтәбез, һәммәгезгә дә озын гомер, балалар куанычы теләп калабыз. Кадерле балалар! Сезгә шушындый матур бэйрэмдэ катнашканыгыз очен рэхмэт!Без сезгә сабырлык, шәфкатьле, миһербанлы балалар булып үсүегезне телибез.

Файдаланылган әдәбият:

1. Закирова Кафия Вәлиевна “Балачак аланы”, РИЦ, 2011
2. Нәкый Исәнбәт “Балалар фольклоры” Казан Татарстан китап нәшрияты, 1984
3. Балалар бакчасында әдәп – әхлак тәрбиясе Методик әсбап өчен аудио – кушымта диск (7, 9, 28.104,138)
4. “Туган телдэ сөйлэшәбез “Методик кулланма очен аудио – кушымта (5, 39, 59)
5. “Төзучесе Илбарис Надиров “Җырлар китабы” Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1972

## Җирле материаллардан файдалану тәҗрибәсеннән

*Сәйфетдинов Рөстәм Равил улы,*
*Яшел Үзәндәге 16 нчы мәктәп директоры, югары квалификационкатегорияле тарих, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Атаклы язучы, галим, педагог Галимҗан Ибраһимов үз вакытында: “Дәрескә алынган һәрбер кисәкнең балага аңлаешлы, рухына яраклы, бигрәк тә мөһиме – гүзәл хисләр кузгата алуыдыр”, – дип язган. Ә хисләрнең иң якыннарын, иң самимиләрен бары тик туган төбәк кенә бирә аладыр. Шуңа да укыту-тәрбия эшендә җирле материаллардан файдалану мәктәбебез үсешенең өстенлекле юнәлешләреннән берсе булып тора. Мин үзем мәктәптә укыта башлаганнан бирле, иң беренче чиратта әтиемнән калган бай лабораторияне кулланып, дәсләремдә укучылар өчен якын һәм кадерле чыганаклардан гел файдалана килдем.

Үзеңнең туган төбәгең мәктәбендә укыту җирле материаллардан файдалану мөмкинлеген, әлбәттә, күбрәк бирә, чөнки үзең кечкенәдән барысын да күреп, ишетеп үсәсең.Җирле материаллар туплауны без мәктәптә мондый юнәлешләрдә алып барабыз:

- Безнең төбәктә табылган матди тарихи чыганакларны туплау һәм аларны мәктәп музеена урнаштыру;
- Төбәгебезнең тарихи сәхифәләрен билгеле бер системага салу;
- Безнең төбәктән чыккан һәм безнең төбәк белән бәйләнешле тарихи шәхесләр турында өйрәнү;
- Үзебез төбәк тарихын яктырткан тарихи, әдәби әсәрләрне, якташ әдипләребезнең иҗатларын өйрәнү;
- Туган төбәк материалларын барлык уку предметларында файдалану.

2017 нче елда без “Федераль дәүләт белем стандартларын гамәлгә ашыру шартларында дәресләрдә җирле материаллардан файдалану” темасына республика семинары үткәргән идек. Әлеге семинар кысаларында мәктәбебез укытучылары, төрле предметлар буенча ачык дәресләр күрсәтеп, җирле материаллар куллану тәҗрибәсе белән уртаклаштылар. 2015 нче елдан башлап, КФУ галиме, тарих фәннәре кандидаты Аскар Александрович Гатин җитәкчелегендә “Тау ягы: тарихы, мәдәнияте һәм рухи мирасы” исемендәге укучыларның төбәкара эзләнү эшләре конференцияләре үткәрә киләбез. Әлеге конференция кысаларында җирле материаллардан файдалану тәҗрибәсен чагылдырган ачык дәресләр, әдәби-музыкаль чаралар да үткәрелә килде. Тарих кабинетында үз вакытында музей почмагы ясаган идек. Еллар

дәвамында анда Тау ягы, аерым алганда Яшел Үзән районы тарихына кагылышлы этнографик, археологик материаллар туплана килде. 2011 нче елда шул ук кабинетта "Алар безгә җиңү бүләк итте!" дип исемләнгән бер почмак эшләдек. Биредә мәктәбебездәге һәрбер укучының, укытучының якыннары, туганнары турында дүрт юнәлештә ("Алар җиңү яулады", "Тыл батырлары", "Сугыш чоры балалары", "Ватанны саклау – һәркемнең изге бурычы") материал туплана башлады. Бу уку елында мәктәпнең 25 еллык юбилеена туры китереп, мәктәбебезнең педагог-оештыручысы, китапханәчесе Садриева Д.С. җитәкчелегендә музей кабинеты булдырылды. Әлеге музейда Тау ягы тарихына, укытучы, шагыйрь, дин эшлеклесе Равил Сәйфтдиновның тормыш юлына, “Сәләт-Яшел Үзән” клубы эшчәнлегенә, мәктәп тарихына кагылышлы байтак уникаль материаллар тупланган.

Татар халкы тарихы үзенең тамырлары белән ерак чорларга барып тоташа. Безнең Яшел Үзән төбәге тарихы да шушы чал тарихның аерылгысыз бер өлеше. Әлеге җирләр безнең эрага кадәр үк фин-угор кабиләләре тарафыннан үзләштерелә башлаган. Бу турыда шул чор кешеләреннән калган матди культура калдыклары дәлилли. Шулай да бу җирләр актив рәвештә Болгар, Алтын Урда Һәм Казан ханлыгы чорларында үзләштерелгән.

Татарстан һәм татар халкы тарихының борынгы чорларын өйрәнгәндә, мин өстәмә рәвештә үзебез төбәктә табылган археологик материалларны кулланырга тырышам. Үземнем туган авылым Мулла Иле авылында хуҗалык эшләре барышында борынгы әйберләр табыла тора. Таштан ясалган кыргычлар, сөяктән ясалган борынгы пычак, энә (мезолит – урта таш гасыр чоры истәлекләре), бронзадан ясалган сөңге очлыгы табылу бу җирләрдә шактый ук борынгы чор кешеләренең яшәгәнлекләре турында сөйли. Күрше-тирәдәге борынгы шәһәрлекләрдә (Өтәк, Тау Иле) булганда, Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорына караган иске әйберләр табылгалый. Музей витриналарындагы экспонатларның шактый өлеше – Мулла Иле авылындагы мин туып-үскән нигездә табылган әйберләр. Сиңа кадәр берничә мең ел элек шушы ук җирдә борынгы кешеләрнең яшәп ятуларын белү күңелдә төрле хисләр уята. Әлеге табылдыклар турында укучыларга сөйләү, аларны күрсәтү, кагылдырып карау балаларда тарих фәненә карата зур кызыксыну хисләре уята, аларның танып белү офыкларын киңәйтә. Мондый дәресләрдән соң алар үзләре дә “казый” башлыйлар. Табылдыкларны тарих укытучысына “экспертиза”га алып киләләр. Аларның кайберләре музей витринасында үз урыннарын таба.

Безнең төбәктәге авылларның тарихлары укучыларда зур кызыксыну уята, чөнки балаларның әти-әниләре башлыча авылдан чыкканнар. Татар теле дәресләрендә топонимика темасын өйрәнгәндә, һәрбер укучы, әби-

бабаларыннан белешеп, үзе кунакка кайта торган авылның чал тарихын язып килә. Әлбәттә, якташыбыз, филология фәннәре докторы Г.Ф.Саттаровның топонимика буенча язылган җитди фәнни хезмәтләре укучылар өчен якты маяк булып тора.

Татар халкының этногенезын өйрәнгәндә, безнең төбәк татарларының күрше чувашлар һәи фин-угор халыклары белән бик тыгыз бәйләнешләрдә торганнарын искәртеп узам. Безнең төбәктәге татар авыллары янында мари сүзләреннән килеп чыккан микротопонимнарның (Чиркәлше – кәкрәйгән, бөгелгән, Мөңгер – чишмә), әлеге авылларда удмурд теленә караган кушаматларның (Пузкар – оя, Туту – каз бәбкәсе) байтак булуы безнең төбәктә кайчандыр фин-угор халыклары яшәгәнлеген дәлилли.

Кешелекнең иң югары кыйммәткә ия булган сыйфатларыннан берсе, мөгаен, Туган илеңә, төбәгеңә, йортыңа булган тирән мәхәббәттер. Социаль тормышка аяк баскан бала бик кечкенәдән үзенең кем икәнлеген, ә иң мөһиме, аның үзенә генә хас тормыш юлы булганлыгын һәм иртәме-соңмы үз томышы өчен җавап бирергә кирәклекне аңлый башлый. Чөнки кеше тормышы яшәү һәм үлем белән генә чикләнми. Чын яшәү ул – үз исемең аша нәселеңне, аның матур сыйфатларын дәвам итә белү. Ә моның өчен үз барлыгыңны, аның тарихи килеп чыгышын аңлау зарури. Кызганычка каршы, безнең балаларыбыз (әти -әниләре кебек үк) хәтта үз бабаларының әтиләре исемнәрен дә әйтә алмыйлар. Мондый рухи фәкыйрьлек киләчәктә җәмгыятьне маңкортлык дәрәҗәсенә төшерергә мөмкин. Ә үзенең үткәнен, бүгенгесен аңлый алмаган кешедән дә куркынычрак зат юк.

Элек-электән төрки дөнья кешесе әти-әнисе ягыннан җиде буынга кадәр нәселен белеп, алар рухына дога укырга тиеш булган. Укымышлыларга тугыз буын бабаларын белү таләп ителгән.

Һәрбер кеше бик кечкенәдән үзенең нинди нәселдән килеп чыгып, нинди юлдан барырга тиешлеген тоеп яшәргә тиеш. Шул мәгълүм: тамырлары нык булмаган кеше тормыш зилзиләләренә каршы тора алмый. Юкка гына шәҗәрә “агач” мәгънәсен аңлатмыйдыр. Тамырлары нык булган агач көчле җилләргә дә бирешмәгән кебек, үз асылын аңлаучылар, үз тамырларын тоючылар тормышта да югалып калмыйлар. Тамырлар ул – безнең бабаларыбыз, бабаларыбызның бабалары, гаилә традицияләре, бабаларыбызның данлыклы эш-гамәлләре, ниһаять, ул синең фамилияң, кушаматың, нигезең, халкың, Ватаның. Кайбер гаиләләрдә иске альбомнар, гаилә ядкярләре, чүп-чарга саналып, аяусыз рәвештә юкка чыгарыла. Менә шулай тамырлар чабыла: кайтарып булмаслык зур ялгышлар ясала. Бөек акыл иясе Ницшеның “Упкынга озак карап торсаң, ул үзе сиңа караячак”, дигән гыйбарәсе бар. Без сәгатьләр буе компьютер, телевизор, смартфон коллары

булып, упкынга тәгәри барабыз, ә нәселебез турында уйларга, балаларыбызга иске фоторәсемнәр күрсәтергә, хатлар укырга вакыт таба алмыйбыз. Ә бөтен нәрсә үз-үзеңне хөрмәт итүдән башлана. Үз-үзен хөрмәт итәргә теләмәгән кешегә гаилә дә, нәсел дә, Туган ил дә кирәкми. Мондый кешеләр турында без тарихтан яхшы беләбез.

Соңгы вакытта генеалогия фәненә – нәсел тарихын өйрәнүгә – шәҗәрәләр төзүгә игътибар артты. Күпләр чын-чынлап үзләренең барлыгын аңларга: белеп булган барлык бабаларын эзләп табарга тырышалар. Бу – бик күп вакыт сорый торган, катлаулы, четерекле, шул ук вакытта кызыклы һәм бик саваплы эш. Соңгы дистә еллар эчендә безнең мәктәбебездә күпләр әлеге изге эш белән янып яшиләр (изгелек – үлгән кешеләрне дә онытмыйча, хөрмәт һәм рәхмәт белән искә алу ул). Үз вакытында мәктәбебездә “Гаилә генеалогиясе” проекты эшләнелеп, гамәлгә ашырыла башлады. Проектның төп максаты укучылар, әти-әниләр, укытучыларда үткән һәм киләчәк буыннар арасында үзләренең арадашчы булуларын аңлау шартлары тудырудан, үз гаиләңә аңлы кызыксыну аша шәҗәрә материалларын туплауда кирәк булган практик белемнәрне, күнекмәләрне формалаштырудан, үз нәселең, Ватаның тарихына горурлык, мәхәббәт хисләре тәрбияләүдән гыйбарәт. Проект гаилә генеалогиясен өйрәнүгә багышланган махсус сыйныф сәгатьләре, әти-әниләр җыелышлары, түгәрәкләр, электив курслар базасында гамәлгә ашырыла. Эш барышында укучылар, әти-әниләр һәм укытучылар генеалогия фәненең төп нигезләре белән танышалар. Иң кирәкле төшенчәләр, законнар, терминнар өйрәнелеп беткәч, үз гаиләләре турында мәгълүмат туплау эше башлана. Табылган һәрбер информация эш барышында анализлана, төрле буыннарның тарихи үсешендә булган закончалыклар табыла, һәрбер нәсел тарихының уртак һәм үзенчәлекле яклары билгеләнә. Эзләнү, тикшерү нәтиҗәләре укучыларның мәктәп, муниципаль район һәм республика күләмендәге фәнни-гамәли корнференцияләрдә ясаган чыгышларында чагылыш таба. Ә иң мөһиме: бала, үз нәселе тамырларын барлау аша, ата-бабалары белән горурланырга, киләчәген дөрес билгели белергә өйрәнә. Кайбер укучылар, үзләренең 7-10 буын бабаларын белеп, бик горурланып йөриләр. Безнең төбәкнең иң атаклы шәҗәрәләре булып ерак гасырларга барып тоташучы Дусмәт, Күгәйби, Тәмти Хатай шәҗәрәләре санала.Тәмти Хатай шәҗәрәсендәге Вәис мулла нәселеннән чыккан 19 гасырда Казанда яшәп иҗат итүче бердәнбер шагыйрь Баһаветдин Вәисов үзен Мөхәммәд пәйгамбәрнең 33 нче буын вәкиле дип санаган.

Яшел Үзән төбәгеннән байтак кына атаклы шәхесләр чыккан. Мәшһүр мәгърифәтче-галим, педагог Ризаэддин Фәхреддиннең нәсел тамырлары да безнең якларга барып тоташа. Аның алтынчы буын бабасы Юлдаш бине

Ишкәй районыбыздагы  Шырдан авылында туып үскән була. Мәшһүр галимнең күпкырлы иҗат мирасын пропагандалау, укучыларны аның  тәрбия, тарих, дин өлкәсенә кагылышлы хезмәтләре белән киңрәк таныштыру һәм укыту-тәрбия процессында куллану йөзеннән  мәктәбебездә “Федераль дәүләт белем стандартларын гамәлгә ашыру шартларында дәресләрдә мәгърифәтче-галим, педагог Ризаэддин Фәхреддин мирасын файдалану” темасына муниципаль  һәм республика дәрәҗәсендәге семинарлар  үткәрелеп килде.

Татар теле дәресләрендә мин аталы-уллы Вәисовлар, К.Насыйри, Р.Фәхреддин тормышларындагы аеруча кызыклы, дулкынландыргыч вакыйгаларны хикәяләгән үзем әзерләгән язмалар буенча изложениеләр, диктантлар яздырам. Укучылар К.Насыйри, Р.Фәхреддин, Вәисовлар, Г.Ф. Саттаров, Х.Гыймадиларның  тормыш юллары, иҗтимагый-фәнни эшчәнлекләре турында белешмәләр, рефератлар, тикшеренү эшләре язалар.

Кеше горурлыгы иң беренче чиратта үзең яшәгән авылың, шәһәрең, нәселең тарихыннан башланырга тиеш. Бала тарих дәреслекләреннән ниндидер бөек кешеләрнең тәрҗемәи хәлләрен укып ятлый, ә үзенә тормыш биргән әби-бабаларының исемнәрен дә белми; чит ил шәһәрләренең барлыкка килү тарихларын өйрәнә – эти-әнисе туып-үскән авылның исеменнән башка бер нәрсә дә әйтә алмый. Ә тарих  ул – Греция, Кытай... тарихы гына түгел, ул безнең төбәк тарихы да, ахыр чиктә без үзебез дә дөнья тарихының бер өлеше бит.

Бүгенге җәмгыятькә рухи-әхлакый яктан нык, үзләренең асылын тирәнтен аңлаучы чын гражданнар кирәк. Үз гаиләсенең, төбәгенең патриоты гынаТуган иле патриоты була ала.

## Дустың булу – зур байлык

*Алкина Наилә Мәхмүт кызы,*
*Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы*
*Осиново бистәсе «В.В. Карпов исемендәге лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Дәреснең максаты:

1. Белем бирү максаты: дуслык темасына  карата өйрәнелгән лексик – грамматик материалны ныгыту, системага салу, эшчәнлекне планлаштыру, аны тормышка ашыру юлларын эзләү, нәтиҗә ясау.

2. Үстерү максаты: укучыларның фикерләү сәләтен, тыңлап аңлау, диалогик һә монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү, сүзләрне үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү.

3. Тәрбияви: дуслыкның кешеләр арасында иң мөһим сыйфат булуына ышаныч формалаштыру.

Бурычлар:

1. Дуслык турында мәгълүмат бирү;

1. татар теленә,дуслыкка хөрмәт ,яхшы караш тәрбияләү;
2. сүзлек байлыгын арттыру, чагыштыра белергә өйрәтү, иң мөһимне аера белү, системалаштыру, иҗади сәләтләрен устерү.

Планлаштырылган нәтиҗәләр:

Шәхси үзеңә һәм башкаларга карата хөрмәт хисе тәрбияләү, парларда һәм төркемнәрдә эшләгәндә башкаларны тыңлый белү, иптәшләрең фикере бедән исәпләшә белү.

Предмет дәреслек белән эшли белү, төшенчәләрне аңлау.

Метапредмет бәйләнешлесөйләмтеленүстерү.

Дәреснеңтибы: алган белемнәрне ныгыту.

Укучылар белән эш формалары: парларда һәм төркемнәрдә эш

Техник җиһаз: презентация, дәреслек,эш дәфтәре, таратма материал

Укытуметодлары:проблемалы, өлешчәэзләнү

Дәрес планы.

1. Оештыру этабы.
2. Дәрескә максат һәм бурычлар кую. Уку мәсьәләсен кую

Тактада:

Дуслык –зур байлык.

Йөз сумм акчаң булганчы, йөздустың булсын.

-Болар нәрсәләр?

- Нәрсә ул мәкаль? (мәкальләрне уку, тәрҗемә итү, аңлату)

- Димәк, без бүгенкемнәртурындасөйләшербез?

- Димәк, без бүген кемнәр турында сөйләшербез?

- Укучылар,нәрсә соң ул дуслык?

Дуслык – ул үзеңнең иң якын кешең белән уйларыңны, серләреңне, уңышларыңны, үпкәләреңне, шатлыкларыңны бергә бүлешү, уртаклашу.

Дру́жба — личные бескорыстные взаимоотношения между людьми, основанные на общности интересов и увлечений, взаимном уважении, взаимопонимании и взаимопомощи; предполагает личную симпатию...

3. Белемнәрне актуальләштерү.

- Узган дәрестә без “Зәңгәр яфраклар” текстын укыдык. Искә төшерик.

- Тыңлагыз һәм сорауларга җавап бирегез.

- Хикәянеңгеройлары кемнәр?
- Лена,Катяданнәрсәсорый?
- Лenaның нинди карандашы юк?
- Катя,карандашларын бирү өчен, кемнәрдән рөхсәт сорады?
- Катя карандашларынбирәме?
- Ничек уйлыйсыз, Катя чын дусмы?
- Катя нинди кыз?

4. Белем һәм күнекмәләрне яңа ситуациядә куллану.

1) “Таркалган сүз”(дуслык)

- Хәрефләрдән нинди сүзләр төзеп булыр?
- Бу сүз ничек ясалган? (сүз ясагыч кушымча ярдәмендә)
- Сүзнең синонимын табыгыз әле (татулык)
- Без сезнең белән дәрестә гаҗәп бер йорт төзербез.Ә дуслык безнең йортыбызның нигезе булыр.
- Йорт төзү өчен тагын нәрсә кирәк?
- Дуслык – ул кешеләрдәге нинди сыйфат? (уңаймы, тискәреме)

2) Сүзләр сайлау.

- Партада сүзләр язылган кирпечләр бар. Алар арасыннан уңай сыйфатларны табыгыз. (тыйнак, гадел, акыллы, көчле, кыю, тырыш, әдәпле, ярдәмчел, эшчән)

- Нинди сүзләр калды? (тупас, әдәпсез, саран, ялганчы, әләкче, куркак, ялкау)

- Алар кешенең нинди сыйфатын белдерәләр? Уңаймы, тискәреме?

- Сезнеңчә, чын дус нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?

Чын дус ... булырга тиеш.

- Ә нинди булмаска тиеш?

Чын дус ... булмаска тиеш.

3) Сингл раунд робин. (Өстәлдә ярдәм соравы) Мин дустыма ........... бирер идем.
Ә хәзер төркемнәрдә эшлик. Сез дустыгызга нинди яраткан әйберегезне бирер идегез, шул турыда сөйләшеп алыгыз. Сөйләшү һәр өстәлнең беренче укучыдан башлана, икенче чиратлашып үз фикерен әйтә. Сезгә аралашуга 10 секунд вакыт бирелә.

4) Җөмләләр белән эш.

- Димәк, чын дусниләр эшли? (булыша, хөрмәт итә, аңлата...) тубәне кую

- Безнең йортның тагын нәрсәләре куелмаган?Аларны куяр өчен безгә укучылар дус сүзенә синквейн язарга кирәк.

Дус (исем)

Ышанычлы, көчле (ике сыйфат)

Сөендерә, юата, булыша (өч фигыль)

Дуслык – ул көч.(мәкаль)

Татулык (синоним)

- Менә өебез төзелеп тә бетте. Бу йортка 6 нчы а класс укучылары җыелган. Әйдәгез, йорт түбәсенә сыйныфны языйк.

- Укучылар без эшләдек,ардык,әйдәгез ял итеп алыйк.Дуслар турында нинди җыр җырлыйбыз әле без (“Җыйдым җиләк”)

5) Бу йортта дуслык саклансын өчен анда яшәүчеләрнең кагыйдәләре булырга тиеш.

- *Хәзер, укучылар, мин сезгә дуслык кагыйдәләрен аңлаткан сүзтезмәләр тәкъдим итәм. Бирелгән кагыйдәләрне дөрес итеп урнаштырыйк әле.* (Укучылар чиратлап тактага чыгып, җавапларны магнит белән урнаштыралар)

- Сүзтезмәләр: алдашмау, дустыңны тыңлый белү, ярдәм итү, кушамат белән эндәшү, исеме белән дәшү, бергә ял итү, кирәк вакытта гафу үтенә белү, елмаю, матур сүзләр әйтү, начар сүзләр әйтү, беркайчан да елмаймау, гафу үтенмәү, тәмле сүзләр әйтү.

| Дуслык кагыйдәләре | |
|---|---|
| + | - |
| | |
| | |

6). Монолог төзү. (укучылар дуслары турында сөйлиләр)

Төркемнәрдә эш

- Укучылар,әйдәгез,нәтиҗә ясыйк.Нәрсә соң инде ул - дуслык?

(Дуслык- ул ике кешенең бер-берсенә ярдәм итеп, авыр чакта булышып яшәүләре. Ул –зур байлык, акчадан кыйммәтрәк, сатылмый торган бөек нәрсә.

| |
|---|
| Дуслык –ул зур бәхет, дуслык –ул ярдәм, дуслык- ул зур байлык. (Экранда) |

Йомгаклау.

1. Рефлексия.

- Без бүгенге дәрестә нинди темага сөйләштек?

-Дәресебезнең максаты нинди иде?

-Максатка ирештекме?

-“Нәрсә ул- дуслык?” соравына җавап таптыңмы?

-Үз белемнәрегезне бәяләгез, әле!

-Кем дәрестә ничек эшләде? Үзегезнең эшегезне бәяләгез.

2. Өй эше:

- дуслык кагыйдәләрен кабатларга;
- дуслык темасына рәсем ясарга яки дустыңа үз кулларың белән бүләк әзерләргә;
- (1- повторить правила дружбы, 2 (по желанию)- нарисовать рисунок по теме “Дуслык” или приготовить подарок другу своими руками.)

3. Укучыларга билгеләр кую.

-Дәресебезне шигырь юллары белән төгәллик:

Тәмле сүзеңне кызганма,
Син дустым сөйләшкәндә.
Ягымлы һәм мөләем бул.
Дустыңа эндәшкәндә.

## Ф.Яруллин “Кояштагы тап”

*Бикмөхәммәтова Ләйсән Гаделҗан кызы,*
*«Татарстан Республикасы Зеленодольск мунииципаль районы Советлар Союзы Герое В.Х. Хаҗиев исемендәге 7 нче гомуми урта белем мәктәбе»муниципаль бюджетгомумибелем бирү учреждениесенең беренче квалификацион категориялетатар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Планлаштырылган нәтиҗәләр

Метапредмет – җаваплылык хисләре, һәр эшне ахырына кадәр җиткерә белү теләге тәрбияләү.

Предмет - Ф.Яруллинның “Кояштагы тап” әсәрен өйрәнүне йомгаклау, тулы анализ ясау, әсәрдә күтәрелгән мәсьәләләргә укучыларның үз карашларын булдыру, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен, фикерләү сәләтен үстерү.

Шәхескә кагылышлы – әниләргә карата шәфкатьлелек, хөрмәт хисләрен булдыру, яхшылык белән яманлыкны аерырга өйрәтү.

Материал: дәреслек

Җиһазлау. Ф.Яруллин “Сайланма әсәрләр”, компьютер, проектор, дәрескә презентация, карточкалар, фотолар, йолдыз формасындагы төсле (кызыл, сары, зәңгәр) фишкалар, 1 укучы ясаган кояш рәсеме.

Дәрес барышы.

1. Дәресне оештыру.

Уңай психологик халәт тудыру.

- Исәнмесез, хәерле көн, укучылар! Кәефләрегез ничек?

- Әйбәт. Кәефләрегез әйбәт булсын.

- Сезнең дә кәефләрегез кояшлы көн кебек булсын.

Таңнар саен хәерле көн телим,
Аяз күкләр телим җиремә.
Кояшлы көн телим бар кешегә
Һәм иминлек телим илемә.

*Ф.Зиятдинова.*

2. Актуальләштерү.

Уку мәсьәләсен кую.

Укытучы. Нәрсә ул яхшылык? Нәрсә ул яманлык(укучылар җавабы тыңлана).

Укытучы. -Балалар, ә хәзер үзегез өчен иң- иң кадерле булган 3 сүз уйлагыз әле. Менә шушы карточкаларга шул 3 сүзне матур итеп язып куегыз.

- Рәхмәт , балалар. Мин күрәм, иң кадерле сүзләр арасында барыбыз өчен дә уртак булган бер сүз бар: ӘНИ сүзе. Ни өчен?

/Көтелгән җаваплар/.

-Чөнки әни иң кадерле кешебез.

-Әни булмаса без дә булмас идек.

-Әни — өйнең матурлыгы, өйнең кояшы.

Әйе, иң беренче торган сүз – әни. Хәзер әни турында яхшы сыйфатларны язып чыгабыз.

(балалар җавабы тыңлана)

Укучылар, нинди матур сыйфатлар язгансыз! Барыгыз да әниләрен бик ярата икән.

Кайсы әсәрдә ана образы, яхшылык һәм яманлык белән очраштык?

-Дәресебезнең темасын билгеләү өчен, игътибар белән экранга карыйбыз. Экранда мәкальләр бирелгән. Мәкальләрдә нәрсә турында сөйләнелә? Аларның эчтәлеген ничек аңлыйсыз?

*Өйнең яме ана белән;*

*Яктылык - кояш янында, яхшылык - ана янында;*

*Ана җылысы – кояш җылысы;*

-Укучылар, бу мәкальләрне нәрсә берләштерә? (Алар барысы да әниләр турында)

- Ә кайсы мәкаль сезгә бигрәк тә ошады, кайсы мәкаль без укыган әсәргә ныграк туры килә?

(Ана җылысы-кояш җылысы)

- Ни өчен ана җылысы кояш җылысы белән чагыштырып бирелә? Әйдәгез шушы сорауга җавап эзлик әле.

3. Уку мәсьәләсен чишү.

Укытучы: - Укучылар, без үткән дәрестә Ф. Яруллинның “Кояштагы тап” әкиятен укып, бүлекләргә бүлгән идек . Бүлекләргә нинди исемнәр бирдек.

1 бүлек. Малайның әнисе авырый.( МАЛАЙ ҺӘМ ӘНИ) Малайның әнисе авырып китә.

2 бүлек. Малай әнисен алдый.(ЯЛГАНЧЫ МАЛАЙ) Малай әнисенә ялган сөйли

3 бүлек. Кояш елмаеп җибәрә.(КОЯШТАГЫ ТАП) Кояш малайны гафу итә.

- Укучылар, әйдәгез әле әсәрнең эчтәлеген искә төшерик.

(Бер укучы әсәрнең эчтәлеген сөйли.)

Сорауларга җавап бирү

- Бу хикәядә төп геройлар кемнәр?

Әни, малай һәм кояш.

Малайның әнисе турындагы юлларны табыгыз әле, балалар.

/Балалар әнисе турындагы юлларны сәнгатьле итеп укып күрсәтәләр. Кояш белән бергә, ягъни бик иртә/.

- Әни кем өчен тырыша соң?

- Көннәрдән беркөнне нинди хәл килеп чыга? Әйдәгез, бу урынны рольләргә бүлеп укыйк әле, балалар.

/Рольләргә бүлеп уку/

-Бу өзектән без малайның нинди сыйфатларын күрдек?

- Ни өчен әнисе суны Көймә тавы артындагы чишмәдән алырга куша? Тексттан шул сорауга җавап табыйк әле.

/ Табалар, укып күрсәтәләр/

- Аның суы тәмле дә, салкын да, шифалы да.

- Малай нинди начарлык эшләде?

- Ул әнисен алдады. Уйнады — уйнады да, үзенең эчәсе килгәч кенә, суны якндагы чишмәдәналып килеп бирде.

Ни өчен кояш ачуланган?

Шул урынны табып укыгыз.

(Укучылар: Кемдер бу дөньяда ялган эш кылган булырга тиеш, улым. Кояшны шул кеше өчен оялудан йөзе каралып чыккан)

Әсәрдән иң төп җөмләне табабыз. (укучылар җавап бирә)

- Бер генә яманлык та эзсез калмый.

Бу әсәр белән автор нәрсә әйтергә теләгән? (төркемнәр фикер алыша)

- Начар эш эшләсәң, барыбер беленә.
- Алдашу – начар гадәт.

Беркемгә дә начарлык эшләргә ярамый

Сабак алган әлеге малай, киләчәктә нинди кеше булыр дип уйлыйсыз?

Мин сезгә гыйбарә укыйм, аның без укыган әкият белән охшаш ягы бар микән?

Бер малай әнисе белән генә тора. Ул, улы начарлык эшләгән саен, рәшәткәгә бер кадак кага бара. Еллар уза, бала үсеп буйга җитә. Беркөнне ул кадакларга игътибар итә һәм әнисе янына килә. Әни, нигә син шулай күп итеп кадаклар кактың? - ди. Әнисе: “ Улым, менә син бер начарлык эшләгән саен мин бер кадак кага бардым. Күрәсеңме, ничаклы алар?” – ди. Улы уйга кала һәм гел яхшылыклар гына эшләргә сүз бирә. Шулай эшли дә. Менә ул да олыгая, әнисе дә карчыкка әйләнә. Әнисе янына беркөнне килә дә: “ Әни, кара әле, рәшәткәдә бер кадак та калмады. Мин яхшылык эшләгән саен берсен ала бардым. Начарлыкларыма каршы яхшылык эшләдем”, - ди. Ә әнисе болай ди: “ Улым, әйе син күп яхшылыклар эшләдең һәм, шулай итеп, начарлыкларыңны бетердең дә кебек, тик әнә, кара әле рәшәткәләргә, никадәр кадак эзләре. Аларның эзләре калган бит”, - ди.

2. Ныгыту.

*<u>Синквейн төзү. (Әни, кояш, малай)</u>*

(Синквейн - биш юллы шигырь. Тәртибе түбәндәгечә булырга тиеш:

Беренче юл - бер исем сүз төркемендәге сүз;

Икенче юл - ике сыйфат;

Өченче юл - өч фигыль;

Дүртенче юл - Билгеле бер мәгънәле фраза. бер җөмлә-метафора;

Бишенче юл - бер сүз - беренче сүзнең синонимы, нәтиҗә.)

*Әни.*

Яхшы, гадел.

Булыша, кайгыра, үстерә.

Әнигә һәрвакыт булышырга кирәк.

Бердәнберем.

*Малай.*

Ялкау, ялганчы.

Тыңламый, елый, алдалый.

Өлкәннәрне тыңларга кирәк.

Өметле.

*Кояш*

Якты, җылы.

Яктырта, җылыта, иркәли.

Кояшта кара таплар булмасын.

Яшәеш.

1. Йомгаклау.

Укучылар, малайга киңәшләр бирегез әле.

IV. Рефлексия

- Автор кояшны кем белән чагыштыра? *(Әни белән.)*

- Ни өчен? *(Чөнки кояш та бер генә, әни дә.)*

- Кояш булмаса, җирдә нәрсә булыр иде? *(Берни дә... Җирдә тереклек булмас иде.)*

- Ә әни булмаса? *( Без булмас идек, яшәү булмас иде.)*

- Нәтиҗә: димәк, кояш та, әни дә бер генә. Шуңа күрә әниләр - безнең өчен иң кадерле кешеләр. Әйе, балалар, әти-әниләрнең сүзләрен тыңлыйк, хәтерләрен калдырмыйк. Аларга кояш гомере телик. Укучылар, әти-әниегезнең, укытучыларның, олыларның сүзен тыңлагыз. Киң күңелле, мәрхәмәтле булыгыз.

Ә хәзер парталардагы сары кәгазь битләрен алабыз һәм үзебезнең яраткан әниебезгә теләк язабыз.

(бөтен укучы да яза һәм тактага беркетелгән сары түгәрәк янына чыгып беркетә)

V. Үзбәя

“5” ле билгесе- барлык сорауларга төгәл һәм тулы җавап биргән укучы кызыл фишкалар ала.

“4” ле билгесе- берничә сорауга җавап тулы булмаса яки 1-2 сорауга җавап бирмәгән очракта уучы сары фишка ала.

“3” ле билгесе - сорауларга җавап һәм төгәл булмаса яки 3-4 сорауга бөтенләй булмаса укучы зәңгәр төстә фишка ала.

VI. Өй эше

1.“Һәрвакыт булсын әни” дигән темага миниатюр сочинение язарга.

2. Әниләр турында мәкальләр язып килергә.